Сочига сәяхәт

Каф таулары артына сәяхәтемнән мин дөньяга карашымны тамырдан үзгәртеп, бөтенләй башка уй-фикерләр, теләк-хыяллар белән кайттым. Тауга карап, тау булып булмый, дигән татар халык мәкале белән бәхәскә керәм: адәм баласы яулый алмаган үр-кыялар юк... Таулардан таулар гына шәбрәк була ала.

6-7 БИТ

Гөлфия Фәйзерахманова:

«Кинода үземне танымадым»

Чаллы театрының танылган артисты Гөлфия Фәйзерахманованың менә дигән балыкчы да икәнен бөтен кеше дә белмидер әле. Иренең туган ягы – Саба районы Олыяз авылына кайтып, балыкка баргач, Нургали әфәндебез кармагын балыклар урап узса, Гөлфия ханым аларны берсе артыннан берсен чүпләп кенә торган.

10 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 31.03.2017 | № 34 (5796)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

КОШЛАР КАЙТА ТУГАН ЯКЛАРГА

1 апрель – Бөтендөнья кошлар көне

Сагындырып, ялындырып, табигатькә яз килә. Карлар эреп, гөрләвекләр ага, өй кыекларыннан тамчылар тама. Яз җиту хәбәрен безгә туган якларына ашкынып кайткан кара каргалар, сыерчык-тургайлар да җиткерә. Күктә аларның тавышларын ишетүгә үк, күңелләр үрсеп, җаннарда яз дәрте уяна...

Зөһрә САДЫЙКОВА

Әбез исә аларны каршы алырга әзерләнәбез. Канатлы дусларыбызга җимлекләр, сыерчык оялары ясау – матур гадәтләрнең берсе. Аеруча авыл җирләрендә бу эш киң җәелдерелгән. Әтиебез белән бергәләп кошларга җимлекләр ясаганыбыз әле бүген дә иң матур балачак хатирәләремнең берсе булып күңелдә саклана. Хәзер дә мәктәп укучылары әти-әниләре белән бергәләп тә, технология дәресләрендә дә кош оялары ясый. Әнә бит Балтач районының Бөрбаш авылы мәктәбе укучылары быел да 110лап оя ясап куандырган кошларны. Технология укытучысы Рим Әкбиров әйтүенчә, алар урмандагы агачларга, мәктәп ишегалдына һәм каенлык полосасына урнаштырылган.

– Алдагы елларда куелган кош ояларын да ачып чистартып торырга кирәк. Гадәттә, бер ясап куйган кош оясы аларга өч ел хезмәт итә. Сыерчык өенә аерым бер таләпләр дә бар. Мәсәлән, ояның эче ышкы белән ышкылмаган, ягъни кытыршы булырга тиеш. Бу кошларга тырнаклары белән ябышып менәргә уңайлы булсын өчен эшләнелә. Аннан соң карга, башка ерткыч кошлар кереп, сыерчык балаларына зыян китермәсенгә, ояга басар өчен таяк та куярга ярамый, тишегә дә артык зур булырга тиеш түгел. Тишек диаметры 4,5-5 см булса яхшы. Аннан соң, кошлар буяу исен дә өнәми. Дөрес, калайдан ясалган бик матур, үзенчәлекле оялар да бар, әмма алар күргәзмә өчен генә эшләнелә. Андый өйне кош яратмый, – ди укытучы.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Авылларда гына түгел, шәһәрләрдә дә әзерләнәләр кошларны каршы алырга. Казан зоопаркы, Бөтендөнья кошлар көне уңаеннан, иң матур кош оясын барлау максатыннан, бәйге дә игълан иткән иде. Аның нәтиҗәләре 2 апрельдә хәбәр ителәчәк. Ул көнне балалар әти-әниләре белән бергә эшләгән эшләрен зоопаркка алып киләчәк.

Күптән түгел генә безнең газета битләрендә дә гадәти булмаган сыерчык оялары ясаучы Вадим Ионов турындагы язма басылган иде. Ул Казанның Е.Г.Ласточкина исемендәге мөмкинлекләре чикле балалар интернат-мәктәбендә технология дәресләре алып бара. Самолет, ботинка, ике фатирлы йорт, песи рәвешендә эшләнгән сыерчык ояларын ясаучы оста куллы Вадимның эшләрен күреп, хәйран калган идек. Урамнарда без элек күреп гадәтләнгән телефон-автоматны да сыерчык оясы итеп күрә ул.

Үз куллары белән ясаган һәр нәрсә кадерле була анысы, ләкин моның өчен сәләт тә кирәк бит әле. Вакыты һәм сәләте җитеп бетмәгән, әмма бик тә яхшылык эшлисе килгән кешеләргә базар, интернет-кибетләр ярдәмгә килә. Аларда кош ояларының бәяләре 350 сумнан башлана, хәтта 2000 сум тирәсендә тирбәлгән җимлекләрне дә очратырга мөмкин. Безгә исә ясаган, элгән йортларыбызда кошлар өздереп сайрый-сайрый оя корсын да балалар чыгарсын иде, дип кенә телисе кала.

ХАЛЫК ӘЙТӘ

- ✓ **Аккош ялгыз яшәмәс.**
- ✓ **Карга килсә, кар китәр.**
- ✓ **Кошның да туган оясы бар.**
- ✓ **Аккош иртә килсә, яз начар булыр, озак торыр.**
- ✓ **Акчарлак килгәч, елгаларда боз тиз кузгалыр.**
- ✓ **Ала карга агач башына кунса, яз тиз, җиңел килер, җиргә кунса, озак килер.**
- ✓ **Апрель аенда торна кычкырса, ел яхшы килә.**
- ✓ **Торна биесә, һава җылыныр.**

minzdrav.tatarstan.ru

Заманча сырхауханә

Казанның 21нче сырхауханәсе 59 меңнән артык кешегә хезмәт күрсәтә. Салмачы, Вишневка, Алтан кебек бистәләрдә яшәүчеләрне дә кабул итәләр бирәдә. Шуңа да Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сырхауханәне зуррак бинага күчерү мәсьәләсен карарга кушкан иде. Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов, Татарстанның сәламәтлек саклау министры Адел Вафин төзелеп килә торган яңа бинаны күреп кайтты.

Бу гади генә сырхауханә булмаячак, консультация-диагностика үзәге ачарга уйлыйлар. Адел Вафин әйтүенчә, үзәктә төрле юнәлештәге белгечләр эшләячәк, амбулатор хирургия үзәге, рентгенга төшү мөмкинлеге, йогышлы авырулар бүлеге, ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне җайга салу да ниятләнелә. Катлаулы операцияләрдән соң авырулар терналкүну курсы да уза алачак.

Идел буе районында яшәүчеләр өчен иң җитди кыенлыкларның берсе – ул эшли торган сырхауханә составында хатын-кызлар консультациясе булмау иде. Хатын-кызларга еш кына ерак арага – Даурия һәм Мәүлетов урамнарында урнашкан сырхауханә белгечләренә йөрергә туры килде. Яңа төзеләчәк бинада хатын-кызлар консультациясе дә ачылыр дип көтелә.

Тагын бер мөһим яңалык – 21нче шәһәр сырхауханәсендә онкология бүлеген булдыру да каралган.

– Белгечләрнең онкологлар белән киңәшләшеп эшләве кирәк. Яман шешне иртә стадияләрдә билгеләү мөһим, – ди Адел Вафин.

Депутат Айрат Фәррахов та бу объектның уйланылган, җитди икәнлегенә басым ясады. Халыкка тагын да уңайлырак булсын өчен, консультация-диагностика үзәге территориясендә машина кую урынын булдыру мәсьәләсе хәл ителәчәген дә әйтте.

КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

Татарстанның товар җитештерүчеләре бик «оялчан»

Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсе быелның февраль аенда Россия күләмендәге эшчәнлеккә рәислек иткән.

– Россия төбәкләрендәге, шулай ук Татарстандагы сәүдә челтәрләрендә монополиягә каршы кагыйдәләрнең, сәүдә турындагы законнарның үтәлешенә кагылышлы мәгълүматны туплау һәм нәтиҗә чыгару безнең идарәгә йөкләнде. Сәүдә челтәрләрендәге 11,2 мең килешү документларының 11 процентында төгәлсезлекләр ачыкланды инде, – диде Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Игорь Павлов.

Татарстандагы сәүдә челтәрләрендә җирле товар җитештерүчеләр белән төзелгән 1 мең сәүдә килешүендә 150 төгәлсезлек ачыкланган.

– Сәүдә челтәрләре, үз кибетләренә теге яки бу товарны сатуга кабул иткәннәре өчен, җитештерүчедән товар бәясенең 10 проценты күләмендә «бүләк» түләве ала иде. Закон нигезендә, ул хәзер 5 процент итеп билгеләнде. Тавык һәм чебеш ите, ипи, сөт кебек социаль продуктлардан 5 процентлы «бүләк» түләве алу закон нигезендә тыелган. Шуңа да карамастан, «Азык» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте («Пестречинка» сәүдә челтәре) социаль продукция җитештерүчедән «бүләк» түләве алган, – диде Игорь Павлов. – «Ак Барс регион» җәмгыяте («Чак-Чак» сәүдә челтәре) җитештерүче предприятие белән товар өчен исәп-хисапны тиешле срогында башкармый.

Сәүдә челтәрләре үзләренең рәсми сайтларында товарлар кабул итүләре турында дөрес һәм тулы мәгълүмат урнаштырырга бурычлылар. Товарны сатуга кабул итү килешүе төзегәндә, «бүләк» түләвен 5 проценттан да күбрәк итеп килешүгә кертергә омтылучылар бар. Россия Федерациясе законнарында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән очракларда, сәүдә челтәре срогы чыккан продукцияне товар җитештерүчегә мәҗбүриләп кире кайтарырга тиеш түгел.

– Сайтта дөрес мәгълүмат урнаштырмау, товар җитештерүчегә зыянлы килешүләр төзү фактлары бар. Товар җитештерүчеләр, үзара сөйләшкәндә, сәүдә челтәреннән зарланалар, ләкин рәсми рәвештә гариза язмыйлар. Товарны сатуга кабул итүдән баш тартырлар, дип шүрлиләр. Сәүдә челтәре законны боза икән, аны вакытында фаш итәргә кирәк. Оялып-курыкып торсак, товар җитештерүчене астыртын «талау» дәвам итәчәк, – диде Игорь Павлов.

Рәдиф КАРАГАЙ.

ЯРМИНКӘ

Фермерларга «яңгырлы» рәхмәт!

Татарстан хөкүмәте карары нигезендә, республика шәһәрләрендә узган ел оештырылган авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә фермерлар 1,6 миллиард сум табыш алган. Бик хуп, хезмәтләренә күрә – әҗере.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, узган ел ярминкәләрдә 12497 тонна бәрәңге һәм яшелчә, 2913 тонна терлек һәм кош ите, 1637 тонна шикәр комы, 1242 тонна он, 166 тонна бал, 16,1 миллион данә йомырка сатылган. Халыкта ихтыяҗ зур булганлыктан, кече ярминкәләр Казанда һәр шимбәдә Яңа ел бәйрәмнәреннән соң да дәвам итте һәм ул май аена кадәр барачак.

Фермерлар сәүдә чатырларында көн саен сәүдә итә. Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Иван Кузнецов әйткәнчә, сәүдә чатырларындагы урын өчен фермерлардан түләү алынмый. Нәтиҗәдә, продукция сәүдә челтәрләрендәге бәяләрдән 20-30 процентка арзанрак. Шимбә көннәрендәге кече ярминкәләрдә «Майский» теплица комплексында үстерелгән кыяр һәм помидорны сатып алу өчен су буе чират хасил була. Казан предприятиеләрендә тарттырылган он, Буа шикәр комы, Чаллыда һәм Питрәч белән Лаеш районнарында үстерелгән тавык-чебеш шәп сатыла. Фермерлар алып килгән ит, сөт шәһәр халкының сумкаларына һәм кул арбаларына күчеп бетә. Казанлылар авызыннан: «Авыл хезмәтчәннәренә рәхмәт! Яңгырлар ясын, уңышлары мул булсын!» – дигән сүзләрне еш ишетәсең.

Казанда фермерлар сәүдәсе адреслары

Фучик урамы, 64; Липатов урамы, 7; Зәкиев урамы, 12; Дементьев урамы, 7; Батыршин урамы, 20; Лаврентьев урамы, 10 һәм Беломорск белән Гудованцев урамнары кисешкән урын.

Сәүдә 7.00-12.00 сәгатьләрдә уза.

Дамир БӘДРИЕВ.

Автор фотосы

Агу таратмагыз!

Табиблар кальян, электрон сигаретлар аша туберкулез, гепатит кебек йогышлы авырулар таралу куркынычы зур дип чаң сукса, җитәкчелек бу замана чире белән законнар ярдәмендә көрәшергә җыена. Дәүләт Думасы депутатлары Марат Бариев белән Николай Герасименко Россия Дәүләт Думасына кальян, электрон сигаретларны сату, куллануны чикләү турында закон проекты тәкъдим итте. Татарстан Дәүләт Советында узган матбугат конференциясендә әлеге закон проекты турында сөйләштеләр.

Эльвира МОЗАФФАР

– Күпләр туклану урыннарында, ял итү паркларында кальян, электрон сигаретлар тартучыларның тирә-якка төтен чыгаруыннан канәгатьсезлек белдерә. Сайлаулар алдыннан депутатларның халык белән очрашуларында да еш яңгыраган темаларның берсе иде бу, – ди Марат Бариев.

Депутат искәртүенчә, 2013 елда «Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирәдәге тәмәке төтененнән һәм тәмәке куллану нәтиҗәләреннән саклау турында»гы закон гамәлгә кергәннән соң, электрон сигарет, кальян, вейп, электрон система аша никотин таратулар аеруча күбәйгән. Тәмәке булып саналмаган бу матдәләрнең составын тикшерүче, аларның сатылуын, кемнәр кулланууын контрольдә тотучы да юк. Хәзер бу мәсьәләдә боз кузгалыр кебек. Марат Бариев закон проектын хупларлар һәм кабул итәрләр дип ышана. Мәскәүдә депутатлар бер җыелышып сөйләшкән дә инде. Дәүләт Советында да бу темага түгәрәк өстәлләр уздырылган. Кальянны, электрон сигаретларны чикләү турындагы закон проектына карата карышы фикер әйтүчеләр табылса да, хуплаучылар күбрәк икән.

gossov.tatarstan.ru

Табиблар әйтүенчә, кальянда гадәти тәмәкедәге кебек никотин бар. Шуңа да кеше аңа ияләшә. Кальян тарту йөрәк-кан тамырлары авырулары, инсульт, инфаркт китереп чыгарырга мөмкин. Татарстанның баш пульмонологы Александр Визель электрон сигарет тарту кеше организмына, зыянлы җитештерү тармагында эшләгәндәге кебек үк, тискәре йогынты ясый дип саный.

Психолог, психотерапевт Рамил Гарифуллин исә кальян сәламәтлек өчен аеруча куркыныч, чөнки төтене кешегә яшерен төстә һөҗүм итә, зарарлы матдәләр организмга зыян сала, ди.

Җәмәгать урыннарында электрон сигаретлар тарту, сату Аргентина, Мексика, Сингапур, Төркия, Таиланд, Венесуэла, Малайзия кебек илләрдә тыелган. Казахстан, Иранда да кальянның сәламәтлеккә китергән зыянын аңлап, аны куллануны чикләгәннәр. «Бездә дә тартучылар белән генә түгел, тәмәке тарту проблемасының үзе белән көрәшкәндә генә нәтиҗәләргә ирешеп була», – дигән фикердә Дәүләт Советы депутаты Светлана Захарова.

– Үсмерләр кафега кереп 50 сумга чәй сатып ала да, көне буе шуны эчкән булып, кальян тартып утыра. Уңайлыклар тудырылмаса, тартучылары да кимер иде,– ди депутат.

Статистика күрсәткәнчә, тәмәке тартуны чикләүгә кагылышлы закон гамәлгә кергәннән соң, тартучылар саны чынлап та аз булса да кимегән.

Закон гамәлгә кергән очракта, кальян, электрон сигаретлар, вейплар тәмәкегә тиңләштереләчәк. Аларны эштә, бина эчендә, җәмәгать урыннарында, гомуми туклану «нокта»ларында тарту тыелачак. Шулай ук кино, спектакльләрдә бу күренешне күрсәтергә ярамаячак. Махсус оешмаларга кальяннарның составын тикшерү хокукы да биреләчәк. Бу матдәләрне сатуга кагылышлы чикләүләр дә кертелер дип көтелә. Тәртип бозу очракларында административ штраф каралачак.

Дөрес, бүген закон кабул ителде дә иртәгә тартучылар саны кимер дип өметләнми депутатлар. Тәмәке, кальян, электрон сигаретлар – болар барысы да бизнес.

– Спорттагы кебек: допингны ачыклыйлар, аның белән көрәш юлларын уйлап табалар, икенче көнгә допингның яңа төре барлыкка килә. Монда да шул хәл булырга мөмкин. Кальян, электрон сигаретлар безнең җәмгыять өчен яңа нәрсә. Шуңа да без аның белән мөмкин кадәр иртәрәк көрәшергә тиеш. Сәламәтлеккә зыян китерә торган бизнес ярдәмендә икътисадны үстереп булмый, – ди Марат Бариев.

СПОРТ

БАСКЕТБОЛ. Казанга Россия баскетбол федерациясе президенты Андрей Кириленко килде. Ул Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, УНИКС баскетбол клубы президенты Евгений Богачев һәм республиканың яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов белән август аенда Казанда Германия, Венгрия, Исландия, Россия арасында узачак иптәшләрчә турнир турында фикер алышты. Андрей Кириленко белдерүенчә, 2023 елда Казан Баскетбол буенча дөнья чемпионатын кабул итәргә мөмкин.

Сүз уңаеннан, бүген – 31 март көнне, Евролиганың 29нчы раунды кысаларында, Казан УНИКСы Белград шәһәренең «Црвена Звезда» командасы белән уйный. Матч 19.00дә башланачак.

ФУТБОЛ. 2 апрель көнне «Казан-Арена» стадионында «Рубин» «Зенит» (Санкт-Петербург) командасы белән очраша. Матч 14.00дә башлана.

ВОЛЕЙБОЛ. 4 апрельдә Россия чемпионаты кысаларында, «Зенит» – «Белогорье» (Белгород) уены була. Матч Казанның «Санкт-Петербург» волейбол үзәгендә 19.30да башлана.

«Мондый хоккей безгә кирәкми»

Хоккей җанатары, үзе дә спортчы, «Татспиртпром» ширкәтенең генераль директоры Ирек Миңнәхмәтовның «Ак Барс»ның «Металлург» командасына чираттагы оттыруыннан соң Инстаграм челтәрендәге битендәге фикере.

«Мин уен нәтиҗәләре белән бер дә канәгать түгел. Матч барышында безнең команданың «Металлург» капкасына ике алка кертүе бары очраклылык иде. Ләкин кичә без Данис Зариповның шәхси ярышын күрдек, нәтиҗәдә ул «Ак Барс»ның җиңелүенә китерде. Аның 2,5 минут эчендә «Ак Барс» капкасына керткән ике алкасы Казан клубының көчсезлеген, анда баручы кадрлар сәясәтенең дөрес булмавын күрсәтте. Моннан өч ел элек Зиннәтулла Билалетдинов Зариповны «Ак Барс»тан китәргә мәҗбүр иткән иде. Татарстан белән бәйле булган шундый көчле уенчыны югалту – иң зур хаталарның берсе, минемчә. Мондый хоккей безгә кирәкми».

Россия Пенсия фонды, үзе тәкъдим итә торган хезмәтләрдән файдалану тагын да җайлырак булсын өчен, мобиль кушымта чыгарды.

Пенсия турында – телефонда

Анда Пенсия фондындагы шәхси исәп-хисап счетының торышын, эш бирүче күчереп барган иминият кертемнәрен күрергә була. Шулай ук пенсия бүлеге белгечләренә язылу, кирәкле документларга заказ бирү мөмкинлеге дә тудырылган.

Бушлай мобиль кушымтага керү өчен дүрт санлы пин-код кертергә һәм дәүләт хезмәтләре порталында авторизация узарга кирәк. Гадиләштерелгән формада теркәлү өчен Россия почтасы, «Ростелеком», Пенсия фонды клиент офисларына мөраҗәгать итәргә була.

– Кушымта ярдәмендә булачак пенсияңне билгеләгәндә, кирәкле балларыңны, иминият стажыңны исәпләргә була. Шулай ук социаль түләүләр, ана капиталы турында мәгълүматны табарга мөмкин, – ди Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге җитәкчесе Эдуард Вафин.

Бензинга бәя арта

Татарстанда февраль аенда бензинга бәяләр арткан иде. Аларга ияләшергә дә өлгермәдек, март азагында тагын бер «күчтәнәч». 92ле бензинның литры 35 сум 40 тиенгә кадәр күтәрелгән, дип хәбәр итә «Реальное время». Дөрес, күпкә артмаган – уртача 50 тиенгә генә. Шулай да бу яңалык машина йөртүчеләрдә канәгатьсезлек уяткан.

Ягулык салу станцияләре җитәкчеләре исә, киресенчә, керемнәр кимеде дип зарлана. Алар, бензин бәясен арттыруны һәм заправкаларда спиртлы эчемлекләр сатуны рөхсәт итүне сорап, рәсми хатлар да юллаганнар. Республикада бензинга бәяләрне Ягулык-энергетика ресурсларын рациональ куллану һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе контрольдә тотарга тырыша. Шулай да бензинга бәяләр тиздән тагын артырга мөмкин дип фаразлый белгечләр.

«Дөнья безнең файдага үзгәрәчәк»

КФУның Лев Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Tataristica» фәнни-белем үзәге татар дөньясы өчен актуаль темаларны уртага салып сөйләшү мәйданы булдырды. Тел, әдәбият, тарих, мәдәният өлкәсендәге мөһим мәсьәләләргә кагылышлы җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү, аерым проблемаларның чишелеш юлларын эзләү, конкрет тәкъдимнәрне резолюция чыгарып, югарыдагыларга җиткерүне күз уңында тота ул. Мондый сөйләшүләр биредә ай саен узачак дип белдерә аны оештыручылар. Беренче очрашуда «Татарның үсеш стратегиясе: шартлар, вазгыять, алымнар» дигән темага сөйләштеләр. Түгәрәк өстәлне филология фәннәре кандидаты Гүзәл Сәгыйтова алып барды.

Расиха ФӘИЗОВА

АКЫЛ МӘЙДАНЫ

– 60нчы елларда Нәкый Исәнбәткә: «Татар милләте ничек итеп гасырлар буе үзен саклап килгән?» – дип сорау биргәч, ул: «Татарны ислам дине һәм мәгърифәт саклап калган», –дип җавап биргән. Сезнеңчә, бүген татарны нинди өлкә саклап кала ала һәм нәрсәгә аеруча басым ясарга кирәк? – алып баручы куйган әлеге сорау сөйләшүнең төп юнәлешен билгеләде.

– Милләтебезнең иң беренче максаты: исәнимин калу. Һәм шуңа таянып, дәүләтебезне аякка бастыру. Шушы юнәлештә барсак, безнең стратегиябез дөрес була. Динебез – милләтне саклап калган төп көч, – диде сәясәтче, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы Индус Таһиров.

Телне саклауда дини факторның роленә, ислам традицияләренә Россия Ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин дә тукталды.

– Бүген без ислам яңарышы дип шатланабыз. Ислам факты безнең тормышыбызда нинди роль уйнарга тиеш? Аны конкрет җирлектә тормышка ашыру – барыбызның да, зыялыларның да проблемасы. Революциягә кадәрге чор белән чагыштырсак, анда татар белән мөселманны бүлеп карамаганнар. Бүген ул бүленгән, – ди ул.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов та дин телебезне саклап калган факторларының иң өлкәне, иң кирәклесе – без инде башка диндә булсак, эреп югалган идек, дисә дә, «динне буган елларда» телне саклауда театрларга да өлешне мулдан бирде.

Язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова татар зыялыларын бергә җыеп шушы сөйләшүне оештыручыларга рәхмәт җиткерүдән башлады сүзен. Әлеге очрашуны ул милләтне коткарырга юл эзләүче «акыл мәйданы» дип бәяләде. Һәм «Милләт үзенең милли дәүләте булганда гына исән кала!» дип, электән булган позициядә калуын белдерде.

– Без хәзер җавап эзлик: шушы дәүләтсез шартта милләтне ничек саклап калырга? Менә сез дөрес әйттегез: патша заманы булган, совет заманы булган – милләт бетмәгән бит. Дин ул – һәркемнең намус эше. Бөтен милләтебезне саклап кала торган урыныбыз – милли мәгариф, милли мәктәп. Патша заманында да безнең милли мәгариф системабыз булган. Милли мәктәпләребез ябылмаган, анда патша түрәләре баш та тыга алмаган, – дип, Фәүзия Бәйрәмова милли мәктәпләрнең ябылуын иң зур югалту дип атады. – Ата-ана, югары белем алсын, дип, баласын урыс мәктәбенә бирә, аннан ул телсез булып чыга. Менә шулай итеп, без милләтне югалтабыз, – ди һәм ул моның өчен безнең законнарыбыз бар дип, милли мәгарифкә, милли университетка кире кайтырга чакырды. Халыкның милли аңын үстерә алмаганга, иҗтимагый оешмаларга да «эләкте».

Җәмәгать эшлеклесе, журналист Римзил Вәлиев алгы сызыкны этно-мәдәни, милли идеяләрдә күрә.

– Милләт өчен дәүләтчелек кирәк дигәнне мин еш ишетәм. Дәүләт кирәк. Аны Исхакый да әйтте. Әмма мин бу тезисны бервакытта да кабатламыйм. Чөнки балалар да, яшьләр дә уйлый: әһә, дәүләт юк… Милләткә карата Россия законнары үтәләме, татар кешесе булган программаларны гамәлгә ашыруда катнашамы-юкмы дигәндә, әлбәттә, үтәлми, – ди ул һәм Арча районы башлыгы урынбасары белән булган бер сөйләшүне мисал итеп китерә: Арчадагы яңа гимназиягә көчкә-көчкә 14 бала тапканнар. – Ата-аналарда милли үзаң таркалу аркасында, милләткә омтылу 90нчы еллардагы кебек түгел.

МИЛЛИЯТ

ДИАГНОЗ КУЕЛДЫ

Сәясәтче Фәндәс Сафиуллинның сүзе һәрвакыт дәлилле була. Без бүген үз телебезгә үзебез хуҗа түгел, дип, ул бүгенге вазгыятьне аяк-кулны бәйләгән хәлдә агымга йөзү белән чагыштырды. Хакыйкать ни кадәр куркыныч булмасын, авырудан, яман чирдән котылу өчен аңа дөрес диагноз кую кирәк, ди ул. Һәм авыруның төп сәбәбе итеп Россиянең милли сәясәтен атый.

– Аның төп юнәлеше – берничә буын эчендә бер телле дәүләт ясау. Һәм ул яшерелми. Шуңа юнәлтеп, безнең күпме хокукларыбыз тартып алынды. Язма телебезгә без хәзер хуҗа түгел. Сөйләм телебез дә чикләнгән. БДИ дигән нәрсәнең мәгънәсен аңлап бетермибез. Ана телендә укып, имтиханны рус телендә бирү ягъни. Ул – балаларны укуын дәвам итү өчен үз теленнән баш тартырга мәҗбүр итү дигән сүз. Мондый законны бер тарихчы да, бер ил мисалында да китермәс. Дөньяда булган хәл түгел. Ирексезләп, әйтмичә генә, әйләнеп үтә торган юл белән, халыкны үз теленнән ваз кичтерү. Димәк, безгә шул законнар белән көрәшергә кирәк. Нинди көч ярдәмендә? Безнең хакимият органнары бар. Дәүләт Советының һәр сессиясе саен бу мәсьәлә күтәрелергә тиеш. Россия Думасында депутатларыбыз бар. Нигә һәрберсе безгә каршы кабул ителгән законнарны кабул иткәндә, «әйе» дип тавыш бирә? Берсе-бер төзәтмә белән чыкканы юк, берсе-бер чыгыш ясаганы юк, берсе-бер кнопкага «каршы» дип басканы юк, – дип, депутатларны да утлы табага бастырып алды Фәндәс ага.

Язучы Ркаил Зәйдулла үз чыгышында милләтне саклау ниятеннән бөтен татар дөньясыннан талантлы балаларны җыеп, туплап заман таләпләренә җавап бирердәй мөмкинлекләре, технологияләре булган элиталы милли мәктәп кирәклегенә басым ясады.

– Милли үзаң ул – беренче чиратта, тел дигән сүз. Тел мәгърифәтсез булмый. Башкортстанда бу мәктәпләр совет чорында ук бар иде. Анда укучылар хәзер башкортларның элитасын тәшкил итә. Шушы сөйләшүдән файдаланып, әгәр мондый тәкъдим белән Президентка чыксак, бу конкрет бер эш булыр иде, – ди ул.

– Бу темага сөйләшүләр, күп очракта, милли мәгарифкә кайтып кала. Республиканың узган елгы социаль икътисади үсеш стратегиясе кысаларында, милли мәгарифне үстерү концепциясе кабул ителде, – ди Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе җитәкчесе Гөлназ Исмәгыйлова һәм конкрет гамәлләр планын тормышка ашыру максатыннан беренче чиратта республикадагы барлык муниципаль идарә җитәкчеләре, район мәгариф идарәсе җитәкчеләре белән сөйләшүләр узуы хакында җиткерде. Бүгенге көндә яңа мәктәпләр төзелә, шуларның берсен татар мәктәбе итү турында сөйләшүләр бара икән.

Татарстан Фәннәр академиясе Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге тарих институтының төп гыйльми хезмәткәре Дамир Исхаков, демократия булмаганда, бер мәсьәләне дә чишеп булмый, ди.

– Ә демократияне кайтару милләт аяк терәп тормаса булмый. Мәгариф системасы да безнең кулда түгел. Татарстаннан читтә эшләр яхшы бара, диләр. Юк. Әйтик, 1990 еллар башында Төмән өлкәсендә 95кә якын татар мәктәбе бар иде, хәзер исә дүрт-биш кенә калды. Татарстан эчендә сакларга тырыштылар мәктәпләрне, әмма һәрбер район үзәгендә дә татар мәктәбе юк, – ди тарихчы.

Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе Тәбрис Яруллинның чыгышы кемнекенә караганда да оптимистрак иде. «Зур шәһәрнең миллилеге юк, дибез икән, бу очракта, менә шул шартларда ни эшли алабыз?» – дигән соравына ул: «Болар безнең көчтән килерлек эшләр, моның өчен ачык структуралар кирәк», – дип, үз схемасын тәкъдим итте. Татарча тәрҗемә үзәкләре ачу; интернет ресурсларны эшкә җигеп, курслар ачу кирәклеге, аларны киләчәктә «үстереп» булуы турында; шәхси татар балалар бакчасын төзү әһәмияте; яшь галимнәргә стипендияләр булдыру, фондлар ачу зарурлыгына басым ясады Тәбрис. Аныңча, интернет, мәгариф һәм сәнгать үз эшен эшләргә сәләтле.

ОПТИМИСТЛАР БУЛЫЙК

Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев исә мондый «чишелмәслек сыман тоелган проблема»лар янында үзенең югалыбрак калуын яшермәде. Тел, милли тәрбия димәктән, ул татарның үз телен кирәксенмәвен баласын яхуд мәктәбенә биргән танышы мисалында да сөйләде. Баласын мәктәп янында көтеп торган танышына: «Нишләп монда укый соң ул?» – ди икән дә, тегесе: «Татар теле белән нишләсен ул», – дип җаваплаган.

– Мин аптырап калдым. Безнең театрда көн дә спектакльләр. Залда – 80 процент яшьләр. Бу яклап төшенкелеккә биреләсе килми. Театр бүгенге көн проблемаларына интуитив рәвештә җавап бирә, – ди ул.

Татар тарихы белгече, галим Искәндәр Гыйләҗев исә янәдән методик яктан камил эшләнгән дәреслекләр проблемасын, кабат кайтып, шул ук элиталы мәктәп мәсьәләсен күтәрде. Чит мәмләкәтләрдә татарны таныту өчен, Европада татар милләтенә симпатия белән караучылар белән мөгамәлә урнаштырырга да кирәктер, юкса безне чи ит ашаучы бер кыргый халык буларак белүчеләр бар, дигән фикерне дә җиткерде ул.

«Пар чыгарабыз. Таралышыйк!» – дип очрашуга нокта куярга җыенса да, театр тәнкыйтьчесе Нияз Игъламов бер үк вакытта Фәүзия Бәйрәмованың сүзләре белән 146 процентка килешүен белдерде. «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррие Миңназыйм Сәфәров «ноктаны» сүз куәтен, сүз көчен белгән журналист буларак куйды: «Әнкәй, әйткән белән әйтмәгән бер булмый, дия торган иде. Халыкны үтерәсең килсә, башта аның фикерен үтерергә кирәк», – дип, ул вазгыятьне үзгәртер өчен халыкка сыйфатлы матбугат тоттырырга кирәклеген тәкрарлады. Индус Таһиров та, очрашуга йомгак ясап, мондый сөйләшүне сукрануга әйләндермәскә чакырды, Фәндәс Сафиуллин да оптимист: «Дөнья безнең файдага үзгәрәчәк», – ди.

Ике сәгатьтән артык дәвам иткән сөйләшүне Казахстанның Астана, Кыргызстанның Бишкәк, Россиянең Санкт-Петербург, Мәскәү, Екатеринбург, Пенза шәһәрләре дә турыдан-туры күрә алдылар. Киләсе очрашу 19 апрельдә узачак. Темасы: «XXI гасыр һәм Тукай».

Илнең иң яхшы IT белгечләре – Казанда

Казанда «WorldSkills Russia» эшче һөнәрләр чемпионатының мәгълүмати технологияләр компетенцияләре буенча сайлап алу этабы үтте. Россиянең 62 төбәгеннән килгән 133 катнашучы арасында иң яхшы белгечләрне ачыкладылар.

«WORLDSKILLS» КӨНДӘЛЕГЕ

tatar-inform.ru

Алисә САБИРОВА

Ярыш барышында беркем белән дә аралашырга, эш урыныннан китәргә ярамый иде. Яшь белгечләр көн саен җиде сәгать дәвамында 127 экспертның таләпчән карашы астында тир түкте. Әлбәттә, мондый шартларда эшләү бик зур психологик киеренкелек тудыра. Бу сиңа БДИ тапшыру гына түгел! Шуңа да ярыш алдыннан һәр студент психолог белән аралаша.

«WorldSkills Russia» чемпионатына сайлап алу этабы биш юнәлеш буенча, Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумы бинасында барды. Бер ел элек техникум «WorldSkills Russia» чемпионатына әзерли торган Төбәкара компетенция үзәге дип билгеләнгән иде. Хәзер биредә республика җыелма командасы ярышларга әзерләнә, ил күләмендә төрле чаралар үтә.

– Узган ел федераль бюджеттан үзәкне җиһазландыру өчен 105 миллион сум акча бүлеп бирделәр. Бу акчаларга дүрт заманча эретеп ябыштыру аппараты, «мобиль робототехника» компетенциясе өчен 10 мобиль робот алдык, иске компьютерларны алмаштырдык. Быел, «басмачылык» дигән яңа юнәлеш булдыру өчен, бюджеттан тагын 80 миллион сум акча бүлеп бирелде. Республикадан бирелгән 150 миллион сум техникум бинасын төзекләндерүгә китте. Заманча материаль-техник база ярдәмендә, безнең студентлар уку йортын әзер белгеч буларак тәмамлый. Эшкә килгәч, аларны яңадан укытырга кирәк булмаячак, – диде Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумы укыту эшләре буенча директор урынбасары Оксана Тимофеева.

Техникум – IT юнәлеш буенча иң күп белгеч әзерли торган үзәк. Техникум студенты Александр Александров мәгълүмати кабельле челтәрләр компетенциясе буенча Әбу Даби шәһәрендә узачак дөнья чемпионатында да катнаша әле. Бүген ул – Россия җыелма командасы әгъзасы.

Ә менә Дмитрий Тиндин «Видео җитештерү» компетенциясендә эксперт дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән. Техникумда бу юнәлештә укытмасалар да, биредә аларны «WorldSkills» чемпионатына әзерлиләр. Дмитрий үз кул астындагы укучысы белән инде Мәскәүдә узган ярымфинал ярышларында III урын алып кайткан. Краснодар шәһәрендә узачак финалда да катнашачак алар.

– Бу һөнәр буенча яхшы белгечләр гел кирәк. Без кинҗырлы һөнәр ияләре: видеога да төшерәбез, монтажын да ясыйбыз, хәтта журналистлар эшен дә башкарабыз. Ярымфиналда ике төрле бирем үтәдек. Беренче көнне 8 сәгать эчендә берәр фильмга монтаж ясадык. Икенче биремдә 15 сәгать эчендә «WorldSkills» чемпионатында катнашкан берәр кешедән интервью алып, аның турында кыска сюжет әзерләдек. Эксперт буларак, мин сюжетларның техник эшләнешен, иҗади ягын бәяләдем, – диде Дмитрий Тиндин.

Бүген IT юнәлешендә эшләгән белгечләр күп җирдә сорала. Ул – тиз үзгәрүчән, һәрвакыт үсештә булган һөнәр. Шуңа да чемпионатта катнашкан белгечләр эшсез калмаячак. «Мәгълүмати кабель челтәрләре» компетенциясен генә алыйк. Аларның уртача хезмәт хаклары – 30-40 мең.

– Ярышта студентлар видеокүзәтү һәм Wi-Fi хезмәте схемасын ясый. Бу белгечләр ярдәмендә безнең өйләрдә телефон, интернет, Wi-Fi эшли. Бәйгедә катнашучы игътибарлы, үз өстенә җаваплылык алырдай, техник әдәбият белән таныш кеше булырга тиеш, – ди «Мәгълүмати кабель челтәрләре» компетенциясе буенча халыкара эксперт Владимир Андреев.

«WorldSkills Russia» эшче һөнәрләр чемпионатының IT-компетенцияләр буенча сайлап алу этабы нәтиҗәләре шушы көннәрдә билгеле булачак.

ЧИСТАРЫНУ

Үзебездән башлыйк!

Татарстанда, матур гадәт буенча, 1 апрельдән санитар-экология икеайлыгы башлана.

– Өмәләрдә аеруча актив катнашкан шәһәрләргә, районнарга, предприятиеләргә, оешмаларга һәм кешеләргә икеайлыкка йомгак ясаганнан соң бүләкләр тапшырылачак, – дип алдан ук искәртеп куйды республиканың экология һәм табигый чыганаклар министры Фәрит Габделганиев.

Эшләгән кешегә мәйдан җитәрлек. Республикада узган ел рөхсәтсез рәвештә барлыкка китерелгән 1877 чүплек ачыкланган, шуның 1689ы бетерелгән. Икеайлыкта бер миллионнан артык кеше катнашкан, 450 мең кубометр чүп җыеп, полигоннарга чыгарылган.

Татарстанда санитар икеайлыкта башкарылган эшләр-чаралар #ЭКОвесна2017 хештегы белән даими яктыртып барылачак.

– Социаль челтәрләрдә Кабан күлендәге аккошның су өстендәге чүпләрне томшыгына кабып, читкә алып куйган видеоязма һәркемне сокландырды. Татарстанда быел – Экология елының, шулай ук санитар чистарту икеайлыгының символы да Аккош, ә шигаре – «Чистарыңны үзеңнән башла». Теләсә кая чүп ташламыйк. Татарстаныбыз чиста-матур булсын! – дип, министр һәркемне өмәләрдә актив катнашырга чакырды.

Икеайлык барышында Экомәктәп, Экогаилә, Экопредприятие, Эковуз, Экобакча, Экоҗәмгыять (экологиягә кагылышлы җәмәгать оешмалары), Экоүзәк (шәһәрләрдәге балалар экология-биология үзәкләре), «Татарстан Республикасының 100 яшел почмагы» номинацияләрендә конкурста катнашып була. Моның өчен тирә-юньне чистартуда башкарган эшләреңне фоторәсемнәрдә яки видеоязмаларда теркәп, министрлыкка юлларга кирәк.

Тышкы төзекләндерү, экология һәм санитар таләпләрне бозсаң, ягъни теләсә кая чүп түксәң, гражданнарга – 1 мең сумнан 5 мең сумга, ә юридик затларга 40 мең сумнан 500 мең сумга кадәр штраф салына.

Дамир БӘДРИЕВ.

Ришвәтче «җаныкаем», тотыласың бит

Казанда 31 майда коррупциягә каршы көрәш буенча Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узачак.

БЕЛЕП ТОР!

Татарстан Республикасының социаль-икътисади мониторинг буенча комитетының «Ышаныч» телефоны – ***(843) 264-72-02.*** *Дүшәмбе-пәнҗешәмбе – 8.00-17.00, ә җомга көнне 8.00-15.45 сәгатьләрдә.*

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы коррупциягә кагылышлы сораулар буенча айның ахыргы чәршәмбесендә 14.00-17.00 сәгатьләрдә кабул итә. Телефон – ***(843) 567-80-99.*** *Дүшәмбе-пәнҗешәмбедә – 9.00-18.00, ә җомга көнне 9.00-17.00 сәгатьләрдә хәбәрләшергә мөмкин.*

– Анда ришвәтчелеккә каршы көрәш стандартларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру юнәлешләре өйрәнеләчәк, – дип хәбәр итте Татарстан Республикасы Президентының ришвәтчелеккә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсенең оештыру бүлеге җитәкчесе Алексей Панкратов.

Татарстан Президенты теләктәшлегендә, республикада 2015-2020 елларга исәпләнелгән коррупциягә каршы сәясәт программасы гамәлгә ашырыла. Хөкүмәтнең электрон порталында «Халык контроле» системасының «Коррупция» кушымтасы да үз эшен эшли. Ел башыннан ришвәтчеләрне фаш иткән 90 хәбәр кергән инде. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, узган ел 925 җитәкченең үз вазифасыннан файдаланып, җинаять кылуы ачыкланган. Муниципаль органнарның – 89, федераль хакимият органнарының – 46, министрлыкларның һәм ведомстволарның 30 хезмәткәрен ришвәтчелеккә бәйле җинаять эше кузгатылган. Ришвәт бирү дә җинаять булып санала, шундый кырын эш башкарырга җыенган 144 кеше җавапка тартылган.

– Ярты елга бер мәртәбә социологик тикшерү оештырабыз. Сораштырулар вакытында кешеләр «иң ришвәтчеләр» дип автоинспекцияне, медицинаны һәм югары уку йортларын атыйлар. Соңгы елларда әлеге министрлыкларда һәм ведомстволарда ришвәтчеләрне фаш итү буенча каты чаралар күрелде, хәзер дә күрелә. Ләкин кешеләрдә шушы мөнәсәбәт-фикер сеңеп калган. Муниципаль районнар арасында өч ел рәттән Әлмәт һәм Минзәлә районнарында муниципаль хезмәт турындагы законны бозуның 50шәр очрагы ачыклана, – дип сөйләде Татарстанның социаль-икътисади мониторинг буенча комитеты рәисе урынбасары Ольга Семенова.

Рәдиф КАРАГАЙ.

ТАУЛАРДАН ШӘБРӘК –

«Ә җәй көне без көньякка ял итәргә барабыз!» Әлеге җөмләне ишетүгә үк, җанга җылы, рәхәт булып китә. Каф таулары артына сәяхәтемнән мин дөньяга карашымны тамырдан үзгәртеп, бөтенләй башка уй-фикерләр, теләк-хыяллар белән кайттым. Тауга карап, тау булып булмый, дигән татар халык мәкале белән бәхәскә керәм: адәм баласы яулый алмаган үр-кыялар юк... Таулардан таулар гына шәбрәк була ала.

СӘЯХӘТНАМӘ

Автор фотосы

ТОРМЫШ ДРАМАТУРГИЯСЕ

Һәр үлем – гыйбрәт, диләр. Сыйныфташым, университеттагы төркемдәшем, күп еллар бергә эшләгән хезмәттәшемне соңгы юлга озатканнан бирле, моңсу уйлар били әле үземне. Аның язмышы: «Син Мокамай, әллә нишләдең, менә алмадың, калдың, югалдың...» – диярлек булды шул. Күңелемнең бер кылы өзелде. Гомер – бер мизгел. Яшәүнең мәгънәсе, вөҗдан ирене, журналист миссиясе, шәхес, чын кеше булу, үз йөзеңне югалтмау, бәхет төшенчәләре торган саен еш һәм ныграк уйландыра башлады. «Мин кем? Ник яшим? Ник нәкъ шул эшләрне мин башкарырга тиеш?» – дигән сораулар килеп баса алга. Мәңгелек рухи кыйммәтләргә җавап эзләү «минне таптыра. Матди байлыклар артыннан куып шашкан дөнья рухи яктан ярлыланды, кешеләр ялгыз калды. Сораулар күп, җавап юк. «Үзең үзгәрмичә торып, дөньяны үзгәртә алмыйсың, бишектән ләхеткәчә гыйлем ал!» – ди хәдис. Кытайга барып булса да. Үзе өйрәнергә теләгән шәкерткә остаз табыла. Дуслар шәхесне камилләштерү буенча семинарга чакыругач, каршы килеп тормадым, бу юлы аларга ияреп, Сочига юл тоттык. 10 мең кешелек семинарда күп сорауларга җавап таптык, мотивация алдык. Ә чын дуслар белән чит җирләргә сәяхәт үзе тагын да искиткеч, гыйбрәтле, маҗаралы тормыш дәресе булды. Кулымнан блокнотым, фотоаппаратым бер дә төшмәде. Хәзер, җәйге яллар якынлашкан чорда, ул якларга юл тотучылар күп, башкаларга да кызыклы булыр, тәфсилләп сөйлим әле.

СОЧИ, АХ, СОЧИ!

Сочины Төркиянең Анталия, Франциянең Ницца, Болгариянең Алтын Комы белән чагыштыралар. Искиткеч шәһәр икән шул ул! Гватемалада «Кышкы Олимпия уеннары – 2014»нең Сочида узачагын белгәч: «Русларның хыялдан кала бер нәрсәләре юк бит!» – дип лаф оручылар булган. Алар хаклы. Җирле халык: «Адлерда сазлык иде!» – ди. Ышанасы килми. Олимпия паркын, Формула-1 трассаларын, Олимпия авылын, кунакханәләрне, спорт сарайларын, аттракционнарны күргәч: «Фантастика!» – дип сызгырып куйдым. Олимпия атмосферасын хәзер дә тоярга була әле биредә! Көчле Россия спортчылары никадәр алтыннар отты, беренчелекне бирмәде бит монда, паралимпия уеннарында бигрәк тә шаккаткыч үрләр яуланды. Олимпия баталияләренә орыну яхшы бәк, уңай тәэсирләр уята, җиңүче буласы килү теләгән көчәйтә. Һәр нәрсә спорт белән шөгыльләнергә, актив тормыш алып барырга кирәклеген искәртә. Бөтен халык өчен ләззәтле ял синонимына әйләнгән шәһәр, Олимпиададан соң, ел әйләнәсендә курортка әверелгән. Швейцариягә тиң Красная Полянада декабрьдән апрельгәчә чаңгы шуалар, майдан ноябрьгәчә Кара диңгездә коеналар... Биредә халыкны Мацеста күкертводород ванналары, биш аквапарк, Джегош үзәнендә 33 шарлавык, Лазаревсктан Пицундага кадәр яр буе манзарасын күзәткеч Ахун тавы башнясы, тагын әллә ниләр, әллә ниләр көтеп тора... Тәнге Сочи – үзе бер романтика! Күп милләтләр яши торган бу шәһәрдә 124 диаспора теркәлгән. Бөтен сорауларны, аксакаллар җыелышып, тыныч юл белән хәл итә икән. Кыскасы, биредәге матурлыкны, игътибарга лаек объектларны, атмосфераны каләм белән генә тасвирлап бетерерлек түгел, үз күзләрең белән күрергә, бөтен күзәнәкләрең белән тоярга кирәк.

«ХАЛЫКЛАР АТАСЫ»НДА КУНАКТА

XX гасырның 30нчы елларыннан башлап, Сочины сарайлар шәһәре дип атыйлар. Байбичәләр өчен түгел, ә эшчеләр өчен сарай. Кем кем диген, халыклар атасы Сталин диңгез ярын шундый итеп күрергә теләгән. «Үнда да, судла да антик стильдәге ике классик сарай төзегез һәм аны эшче сыйныфка бүләк итегез!» – дигән юлбашчы. Колонналы шифаханәләрдә совет заманасында, нигездә, шахтерлар һәм металлурглар ял иткән. Ул архитектура бүгенгәчә шәһәр бизәге булып тора. Диктатор һәм шәхес Иосиф Виссарионовичка карата җәмгыятьнең бердәм фикере һаман юк: дәһшәтле сугышны кичкән ветераннарның фашизмны җиңгән генералиссимусны ничек яклавын үземнең ишеткәнем бар. Күз алдымдагы бу сарайлар, һәр адымда ярылып яткан матур эзләре аны яхшы яктан гына шәрехләде бит әле менә. Кызы Светлана Аллилуеваның «Дуска егерме хат» дигән китабыннан аның бик кайгыртучан әти булуы, радикулит белән чирләве, Сочидагы мацетин ванналарын кабул итүе турында укыгач, моңсу да булып китте. Бер караганда, гап-гади кеше язмышы инде. Берия белән дә шушында танышкан икән. Гид Сталинның биредә ял итүе белән бәйле бер кызыклы тарих та сөйләде. Аның ролен берничә фильмда башкарган актер Михаил Гелавани, үзен юлбашчыга якынайдым дип уйлап, «Зеленая роща» дачасында берничә көн ял итәргә теләк белдерә.

– Нәрсәгә ул аңа? – дип сорый хат тапшырган ярдәмчесеннән Сталин.

– Артистның бөек образга тагын да яхшылабрак керәсе килә.

– Ә сез аңа бу дачадан түгел, ә мин сөргендә утырган Турухан өлкәсеннән башларга киңәш бирегез.

Менә шулай! Гади кешеләр анда үтеп керә алмаган, билгеле. Узган гасырның 80нче елларыннан башлап, бөек диктатор биләмәләрен экскурсантлар басып ала. Бу юлы анда эләгеп булмады, ярар, «Яшел Замок»ка яңадан тагын юл бер төшәр әле...

АХУННАН ТӨРКИЯ КҮРЕНӘМЕ?

Мацеста һәм Хоста елгалары арасындагы Ахун тавының иң биек ноктасына мендек. Сталин указы белән, 1935-1936 елларда архитектор С.И. Воробьев тиз арада урта гасырларның роман стилендәге рыцарьлар замогы төзи. Биредә шул еллар романтикасы: музыка уйнап тора, фотога төшәргә мөмкин. Спираль баскычлар (киңлеге юлбашчының итекләре зурлыгында ясалган) буйлап өскә үрмәлибез. Диңгездән 663 метр югарылыкта басып торабыз. Күк йөзенә бик якын, болытларны менә-менә тотып алырбыздыр кебек. Җәйрәп яткан Кара диңгез Кавказ таулары белән очраша. Нинди хозурлык, манзара! Әйбәтләбрәк карасаң, Төркия дә күренә, диләр. Күрмәдем күрүен.

РОЗАНЫҢ «ЙОЛДЫЗ СӘГАТЕ»

Юлдашларыбыз – берсеннән-берсе хикмәтле кешеләр. Ярты Мамадышны инглиз теленә, хыялларның чынга ашуына ышанырга, җиңү яуларга өйрәтеп бетерергә озасыбыз Роза Мәхмүтованың туган көне бүген. Иртәннән котладык, җыйнаулашып, Сочи тирәли сәяхәткә чыгып киттек. Красная Полянада, тауларда йөрдек, менә автобус безне... Роза Хутор дигән җиргә алып килде. Дөнья күләмендә популярлык яулап өлгергән тау чаңгысы курорты бу. Биредәге матурлык, күркәм архитектура, цивилизация каршында Европа ял итә, диләр. Талгын җил исә, таудан тауга йөртә торган канат юллары башка орынып диярлек узып китә, ике индус, йөрәкләрне өздереп, «Ялгыз көтүче» көен уйный. «Роза Хутор» дип язылган төрле төстәге дистәләгән әләмнәр җилферди. Розаның көне бүген, йолдыз сәгате! Хыялларның чынга ашуына барыбыз да исебез китеп, хозурлыкка сокланып, төркемебез белән басып торабыз шулай. Карасак: безнең семинарда чыгыш ясаган иң текә лидерларыбыз – миллионерлар да шушында ук ял итеп йөри икән. Безнең белән фотога төштеләр, уңышлар теләделәр. Джеймс Вади дигәне – «Бриллиантлар Альянсы» укыту системасының җитәкчесе. Аның үзенең тормышы турында язган «Иреклә кеше бул!» («Стань свободным человеком») дигән китабын укыганым бар. Хатыны ташлап киткән, кредитларын түли алмаган гаҗизлектән, ул атылып үләргә уйлый, пистолетын чигәсенә тери. «Йа Ходам, күреп торасың, мин үз иркем белән синең хозурыңа китеп барам, булсаң, миңа бер әр билге бир!» – дидем. Шкаф алдына китап бердәнбер китапка – Библиягә күзем төште. Австрия чигеннән атлап кергән һәркемгә тоттыралар аны. Уртасыннан ачтым, укыйм: «Уйларыңда сак бул, синең тормышыңны нәкъ менә уйларың формалаштыра» («Будь осторожен в своих мыслях, ибо твою жизнь формируют твои собственные мысли»), дигән җөмлә мине айнытып җибәрде, чыннан да, шулай бит...» – дип яза ул. Джеймс Вади – менә ничә еллар инде бик зур уңышларга ирешкән, үзен җан белән тән тәңгәллегендә яшим дип санаучы ир-ат, меңләгән кешеләрне бәхетле, тәвәккәл булырга өндәп, семинарлар үткәрүче бизнес-тренер. Безне – шәкертләрен, фитри иман белән бәхетле булырга яратылган адәм балаларын, гыйлем алырга, аралашырга, үзгәрергә, үсәргә, яратырга, һәр көннең кадерен белеп яшәргә, рухи һәм матди байлыкка омтылырга, хәр фикерләргә, игелекле гамәлләр кылырга өнди ул. Рәхмәт, остазларым!

АБХАЗИЯ – ҖАН ИЛЕ

Шушы кадәр юл үтеп килгәч, Сочига орынып торган Абхазияне дә күрмичә китеп булмый инде. Төркемебезгә махсус автобуска заказ бирдек тә таң белән юлга кузгалдык. Сәгатьтән артык чират торып, чып-чын таможняларны узып, Абхазия җиренә аяк бастык. Гид итеп Марина исемле хатынны билгеләделәр. Кызыклы нәрсәләрне күп сөйләде ул.

Абхазия картасына самолеттан карасаң, бик зур «И» хәрефен, тагын бик үк анык булмаган «Н» һәм «В» хәрефләрен күрергә була, ди. Инициаллар формасындагы кипарис аллеяларын моннан 100 ел чамасы элек рус сәүдәгәре Николай Игумнов утырткан... Бу шәхес язмышы турында әсәр язарсың, билләһи. Беренче гильдия сәүдәгәре үзенең байлыгы белән генә түгел, чиксез фантазиясе белән дә тира-юньдә дан тоткан. 1901 елда ул үзенең Якиманкадагы әкияти йортына кунак җыя. Гаҗәпләндерү өчен, идәнгә тәңкәләр сибә. Кунаклар, алтынны чыңлатып, очынып-очынып вальс биилә... Әләкчеләр кайда да бар: императорга шул ук кичтә хәбәр җиткерелә: «Сезнең сурәтегезне таптый-таптый биеделәр!» Николай икенче сәүдәгәрне ерак җирләргә сөрергә боера. Ә ул җирләр Сухум губернясының малярия таратучы озынборыннар, агулы еланнар мыжгып торган сазлыклы диңгез яры булып чыга. Патша җәберенә дучар булган сәүдәгәр шушы һәлакәтле урында 6 мең дисәтинә җир сатып ала...

ТИК ТАУЛАР

Доннан 150 балыкчы алып килеп, диңгез буенда консерв заводы ача. Хезмәт хакын яхшы түли. Эшчеләргә ул вакытта күрелмәгән уңайлылыклар белән тулай тораклар, гаиләлеләргә йортлар төзиләр, бераз эшләгәч, ул йорт, җире белән бергә, аларның шәхси милкенә күчә. Аннары сасы сазлыкларны киптерергә керешә: 800 эвкалипт (ул суны насос сыман үзенә суыра икән бит, сазлык киптерү өчен менә дигән агач), йөзләгән кипарис, пальмалар, самшит, магнолия агачларын күпләп утырта. Диңгез буйлап баржа белән уңдырышлы Кубань туфрагын ташыйлар. Киптерелгән урыннарда Ярославльдән китерелгән нәселле сыерлар үрчетелә башлый. Аның иң яраткан шөгыле – искиткеч экзотик бакча. Мандарин, виноград, киви, манго, тәмәке, камфара плантацияләре... «Абхаз бамбугы» предприятиесе эшләп китә. 1917 елгы революциядән соң Игумнов үзенең биниһая зур хуҗалыгын яңа властька ирекле рәвештә бирә. Гаиләсе белән Франциягә эмиграцияләнү мөмкинлегеннән дә баш тарта. Үзенең җирендә яңадан ачылган Өченче Интернационал исемендәге цитрус җитештерү совхозында гап-гади агроном булып эшли. 1924 елда вафат була. Каберенә үзе яраткан кипарисларны утыртып, тыйнак кына күмеп куялар. Аннан соң күп сулар аккан, заманалар, властьлар күп алышынган Абхазия җирендә. Халык хәтере яши. Аның турында бик матур легендалар йөри. Пицунданың җәннәт бакчасын хәтерләткән урыннарында: «Аны Игумнов утырткан... моны Игумнов төзегән... Аңа чиста алтыннан һәйкәл кую да аз. Ул – безнең рус туганыбыз», – дигән сүзләр белән еш очраштык. Исемен мәңгеләштерүгә лаек шәхес. Гел кешесез урында Гагра курортын төзетүгә гомерен багышлаган принц Александр Ольденбургскийны да хөрмәт белән искә алдылар. «Яңа руслар» кайда да бар. Монда да килгәләгәннәр. Берсе әнә җир сатып алган, алагаем сарай салган, аны кремльнекедәй монолит кызыл кирпеч стена белән әйләндереп алган. Шунда ук пляж кисәген дә эләктергән...

«ЧИТ МОНАСТЫРЬГА ҮЗ УСТАВЫҢ БЕЛӘН КЕРМИЛӘР!»

Аллаһы Тәгалә үзе тудырган шундый җәннәт почмагында агрессиягә тамчы да урын булмаска тиеш бит инде. Лев Толстойның «Набег» дигән хикәясеннән юллар искә төшә: «Трудно понять, как, среди этой изумительной красоты, среди цветущей природы и гордых гор, человек может испытывать чувство ненависти, быть таким жестоким и злобным...» Әйе, аңлавы кыен, тик XX гасырның буеннан-буена барган абхаз-грузин конфликты турында яхшы беләбез. 1992 елда биредә сугыш килеп чыга. Аның эзләре һаман бар шул әле, йөрәк яралары да саркый. Яшь илнең хәрабәләрне торгызырлык рәте юк.

– Акчагыз – рубль, кая китәрсез инде?! Россиядән тагын берәр Игумновны сөргенгә җибәргәннәрен көтәсез бугай?! – дип куйганымны сизми дә калдым.

– Һәркем үз өендә тыныч, мөстәкыйль яшәргә тиеш, башкалар белән бер-берсенә матур итеп, кунакка гына йөрешеп. Шулаймы?! Чит монастырьга үз уставың белән кермиләр, – диде дә миңа аркасы белән үк борылып басты Марина.

Аның фонында ачык уч төбе сурәтләнгән әләм җилферди иде. Соравым өчен үземә дә уңайсыз булып китте, кунак булсаң, тыйнак бул, Алсу, тылмачлыгың җитеп бетмәде бугай, әйдә, мизгелне тот! Әнә бу биек таулар, колач җәеп йөзәрлек диңгез, искиткеч табигать – миллион ел шушылай яшәгәннәр, дөнья матур, дөнья киң, кешеләр генә үзара уртак тел таба алмыйча, сугышып ямьсезли аны. Җир, байлык бүлешәләр, һаман нидер җитми. Ә бит һәммәбезгә өч аршын җир җитә. Һәр мизгелнең кадерен белеп, дуслар белән яшәп калыйк! Алдыбызда – легендар Пицунда шәһәре. Диңгез суының иң чиста урыны да шунда, диләр. Бухтада урнашканлыктан штормнар да булмый икән. Гүзәллеккә чик-чама юк. Ишетүемчә, данлыклы язучылар курорты да бит әле бу, эх, ничек кенә язучы булырга инде, ә?!

КҮЧТӘНӘЧ

Диңгез яры буенда безне кырыктартмачы әбиләр сырып алды. Кызыл җепкә тезелгән лавр яфраклары веногын берсе муеныма ук кигертеп куйды. Кулыма эвкалипт себеркесе тоттырды. Ничарадан бичара, акчамны түләдем инде. Торам авызымны ерып басып: пьедестал гына җитми. Тик бу халәтем озакка бармады, әбиләрнең икенчесе: «Галядан мең тәңкәлек әйбер алдың, ә мине буш калдырасыңмы?» – дип килеп бәйләнде. Чача, үзе ясаган коньяк тәкъдим итә. Менә аңлатып кара син аңа базар мөнәсәбәтләрен, хәмернең тамчысы да хәрам икәнен... Аджика салынган банкасын: «Кавказда иң популяр тәмләткеч, иң гади блюдога да үзгә тәм кертә», – дия-дия, сумкама шудырды барыбер. Безне, тауга менешли, өй сыры ясый торган йортка алып керделәр. Шәраб җитештерүчеләрнең подвалы кибетенә тукталдык. Кул белән җыелган чәй, чикләвекләр, умарталыктан тау балы алдык. Чурчхелла – Абхаз сникерсы бигрәк ошады. Җепкә чикләвек тезәләр дә куертылган җимеш согына тыгалар. Глюкоза һәм фруктоза исәбенә бик тәмле, туклыклы әйбер, менә дигән үзгә бүләк килеп чыга. Кулдан ясалган хәнҗәрләргә, сарык тиресеннән тегелгән киемнәргә, чуарлап бәйләнгән йон оекбашларга да озаклап карап тордым... Сумка күтәргесез булды бит инде, бу шешәләрне самолетка керттермәсләр, мөгаен. Чама белергә кирәк. Акча су урынына ага монда...


amazonaws.com

ЗӘҢГӘР КҮЛ

Юл өстендә Зәңгәр күлгә тукталдык. Аның турында ике легенда сөйләде Марина. Легендалар – минем иң яраткан жанр, тиз-тиз блокнотка терким.

Тауларда көне буе йөреп алҗыган аучы юынып алырга уйлый. Күлдәге шәүләсеннән үзенең яшәргәнен күрә. Хатыны башта танымый тора, аннан сорау ала да, күлнең кайда икәнен белгәч, шунда чыгып йөгерә. Карт хатынын озак көтә, тегесе юк та юк. Күл янына баргач, адашкан кечкенә кызчыкны табып алган, ди. Һеем, алай икән. Кая, без дә хикмәтле су белән әйбәтләп юынып алыйк. Кайсы хатын-кызның яшәрәсе килмәсен инде! Әллә ни аерма сизмәдем сизүен. Озаграк торырга, ешрак юынырга кирәктер бәлки?! Безне гид, сәгатенә карап, ашыктырып кына йөртә шул. Икенче легенданы тыңлыйбыз. Борынгы заманнарда бу тирәләрдә мәгарә булган, имеш. Анда зирәк аксакал яшәгән. Күзләре гадәти булмаган зәңгәр төстә икән моның. Яшь чагында ул аучы булган. Яшь аучылар аның янына киңәш-табыш итәргә, серләр белергә килгәннәр. Аудан кире кайтканда, рәхмәт йөзеннән, затлы киек тиреләре, ит калдыра торган булганнар. (Менә бит белем, тәҗрибә ничек кыйммәт тора!) Тик бервакыт, яңгырлы көндә, монда чит кабилә төн кунарга килеп кергән. Карт аларны кунак иткән, ашаткан-эчерткән, аю, болан, зубр, кыр кәҗәсе тиреләре өстенә урын җәеп биргән. Чакырылмаган кунакларның бу байлыкка күзләре кызган, хуҗаны үтереп, урламакчы булганнар. Планны тормышка ашырып, чыгып китәбез, дигәндә генә, мәгарәгә көчле су агымы ургып килеп кергән. Шушы урында хәзер Зәңгәр күл ди. Яхшылабрак карасаң, су астында калган мәгарә төбендә картның зәңгәр күзләре чагыла, ди.

ХЫЯЛДАГЫ РИЦА

Хыялларның чынга ашуына ышанмас җиреңнән ышанырсың. Безнең кухняда бер картина эленеп тора. Ашап утырганда шуңа карыйм да: «Эх, шушы күлләрне бер барып күрсәң иде!» – дип куйдым быелгы кышта. Исемен дә, кайдалыгын да белмәгән килеш. Алдыбызда шул сурәттәге күл пәйда булгач, авызым ачылды да калды! Рица күле! Теге як ярда Сталин дачасы күренеп тора. Тагын Баш командующий төребкәсен тартып уйланып утырган җирләрдә басып торабыз, эзләренә басып йөрибез! Хәерлегә булсын! «Аллам үзең алып чык!» юлының өземтәсен күргәч тә, серпантин юллардан аска күз төшерсәң дә, кот ботка төшә; икегә ярылган кыя арасыннан үткәндә, өскә карасаң да, аска карасаң да – баш әйләнгеч хозурлык, очсыз-кырыйсыз киңлек, иркенлек. Һә-һә-һәәәәәәй, дип кычкырсаң, яңгырап кайтаваз ишетелә. Саф һавадан, тау буйлап йөгергән Бзыбь елгасының тизлегеннән, хөрлектән, барысыннан, барысыннан да әйләнә ул баш. Бөркетләр генә менеп җитә алган бу урыннарны ничек каләм белән тасвирлап бетерәсең, сүзләр генә җитми, шалт та шолт фотога төшәбез. Вакыт тукталды, дөнья матур, дөнья киң! Әнә берсе шул фикерне элмә тактага язып, эскәмия өстенә кадаклаган: «Жизнь прекрасна!» Тагын да өстәрәк күрмәгән җирләр күп калды әле: Ауадхара минераль сулары, Альп болыннары, тау өстендәге күлләр, кыялар артында Россия чиге килеп тоташа, диләр. Ерак түгел икән, алары башка вакытка калып торсын... Табигатькә сокланып йөрү бүгенгә җитәрлек булды. Шәхесне камилләштерергә булганбыз икән, рухи үсешне дә уйларга кирәк. Әйдәгез, кич җиткәнче, данлыклы Яңа Афон монастырена өлгерәсебез бар!

ЯҢА АФОНДА

Яңа комплекска Грециянең иске Афон монастере изге Пантелеимон аксакаллары 1875 елда нигез сала. Тау-ташларны кисеп, меңләгән тонна җир чыгарып, никадәр көч-куәт кертеп, катлаулы юллар төзеп ясалган гыйбадәтханә бу. 1917 елгы революциягә кадәр Яңа Афон Кавказның иң әһәмиятле рухи мәркәзе була. 1924 елда «контрреволюцион агитация» өчен властьлар тарафыннан ябыла. Биредә склад, ял йорты, 1992-1993 грузин-абхаз конфликты елларында хәрби госпиталь дә була. Ышанучыларга 1994 елда кире кайтарыла. Аның эчендә әле бер тапкыр да реконструкция булмаган. Сугыш вакытында снарядлар эчкә үтеп кереп тә шартламыйча калган, имеш. Стеналарына сурәтләнгән изгеләрнең ни әйтергә теләгәннәрен аңларга тырышырга кирәк, һәркайсының тирән мәгънәсе бар, диделәр. Монахлар хәзер дә яши. Нәрсә мәҗбүр итә адәм баласын шушы дөнья гүзәллекләрен калдырып, монастырьга китәргә? Икенче килгәндә, үзләрен сөйләштерермен әле. Әйе, Марина әйткәнчә, чит монастырьга үз уставың белән кермиләр. Без монда кунак кына, йөрибез тыйнак кына...

ЭПИЛОГ

Инде җеп өзәрлек тә хәл калмаган, арылган, тик без бик канәгать. Бер көнлек чит илдә булдык бит. Җан илендә. Автобуста абхазча җырлар тыңлап, йокымсырап кире кайтып барабыз. Фара яктыртудан ары җирне күреп булмый, тик без кая юл тотканны беләбез. Тормышта да шулай: хыяллары, максаты әллә кайларга илтеп җиткерә адәм баласын. Тик беркайчан да, беркайчан да бирешмәскә, алга таба атларга кирәк! Колакта – диңгез шавы, тирә-юньдә – акияттәге түгел, чынбарлыктагы Каф таулары. Таулардан шәбрәк таулар гына була ала! Иншалла, аларын да яуларбыз...

Алсу ДИЯР,
Сочи – Абхазия – Мамадыш.

«Әсәрне исем белән үлчәү – зәвыксызлар эше»

ФИКЕР

Тукай премиясенә чираттагы көрәш дәвам итә. Моңа кадәрге премияләр бүлү-бүлешү тарихы аның хакында ни генә язсаң да нәтиҗәсезлеген исбатлавына карамастан, Галимҗан Ибраһимовның март аендагы мәртәбәле юбилее уңаеннан иҗаты белән тулысынча танышып чыгуым узгандагы тәнкыйтькә кайтырга, акыллы кешеләрнең инде әллә кайчан язылган сүзләре һаман да искермәгәнлекне тагын бер кат күрергә һәм кулыма каләм алырга мәҗбүр итте.

Рифә РАХМАН

Икенче бер сәбәп: Тукай премиясен дәгъвалаучылар исемлегенең зурлыгы, чуарлыгы һәм кайбер исемнәрне укып киткәндә, бу кешеләр милли барышыбызга нинди өлеш керттe, алар Тукай йөзенә кызыллык китермәслек иҗтимагый активмы, аларны кем укый, алардан кем өйрәнә: иҗатташларымы, зәвыклы катламмы, әллә тулы бер гавамммы, дигән сорауның тууы. Сәбәпнең өченчесе: Муса Җәлил премиясен кемгә бирүнең бу елда бик кызык кына, күңелне төшерерлек дәрәҗәдә хәл ителүе. Сүзне шуннан башларбыз да.

Җәлил бүләге, Тукайныкыннан кала, икенче урында торадыр. Хөкүмәтебезнең яшьләрнең алга китешен, милләт тормышында зур роль уйнавын, сүз сәнгатьләребезнең язмышын кайгыртып уйланылган премия ул. Кайчандыр бик үлчәп, бик уйланылып кына бирелгән премия. Күрәшче шагыйрь исемендәге Дәүләт бүләген Зөлфәт кебек олы талантның да озак еллар ала алмаган елларны хәтерлим. Ә бит күңелебезне үсендереп, гаделлеккә өмет уятып алды! Дөрес, премиянең язмышын хәл итеп утыручылар бер төркем яшьләрнең аның иҗатының зурлыгын, Зөлфәтнең милли әдәбиятны үстерүдәге ролен кабинетларга бәреп кереп дәлилләп бирүенә колак салгач алды. Шул чакта иманлылык үрнәге күрсәтеп, шушы адымга барган премияләр бирү комитетына күңелдә зур рәхмәт хисе яши.

Инде бу елдагы бүләк алучылар исемлегенә карыйк. Каләмдәшләребездән аны кем дәгъвалады да, кемгә эләкте соң? Калганнар турында сөйләүне башка бер вакытка калдырып, лауреатка мөнәсәбәтле фикер әйтеп үтәсе килә. Җәлил бүләге әдипләрдән нибары бер кешегә – Язучылар берлегендәге вазифасы буенча да яшьләр белән күп эшләргә тиешле һәм аның өчен хезмәт хакы да алган, Рәмис Аймәткә бирелде.Ул, әлбәттә, Җәлил премиясен иҗат куәсе, талант зурлыгы, язганнарының рухи-сәнгати кыйммәте өчен алмады, чөнки инде яше 35тән күптән узган иде, шагыйрь премияне яшьләр иҗатын үстерүгә әллә керткән, әллә кертмәгән бармак очы кадәр өлеше өчен дәгъвалады.

Башта Рәмис каләме турында берничә сүз. Яхшы язамы? Яхшы. Камера әдәбиятының алгы сафында бара. Көрәшче шигърияте, публицистикасы, прозасы бармы? Юк, әлбәттә! Ул үзенең характеры белән дә көрәшчеләр арасында була алмый. Көрәшчеләр бүләген көрәшчеләр генә, милләт язмышын кайгырту хәрәкәтендә үз позицияләрен булдырганнар һәм бернинди шартларда да шуннан ваз кичмәгәннәр генә алырга тиеш! Тукай премиясен бигрәк тә!

Син гомереңне яшьләр белән эшләүгә багышлагансың, еллар дәвамында үз акчаңа аларның китапларын чыгаргансың, көн саен кемнеңдә булса язганнарын редакцияләгәнсең, даими рәвештә консультацияләр багышлагансың, алар иҗатын тәнкыйть мәкаләләреңдә яктыртасың, «Әдәби судлар» аркылы уздырасың, әллә никадәр язучы үстереп биргәнсең, шул эшеңне вуздан тыш та дәвам итәсең, иң мөһиме: мәкаләләрең белән милләтнең яшәве өчен көрәшәсең... әмма Җәлил исемендәге премия тирәсендәге гауганы күреп, аны бүлешү көннәрендә еракка китеп качасың, үзеңнең исемеңне лаексызлар арасында күрергә теләмисең.

Ихластан белдерәм: мине кандидатларның кемлеге, социаль чыгышы, статусы түгел, әйткәнемчә, иҗтимагый йөзе, каләмдәшләре арасында шәхес буларак бәһасе һәм, әлбәттә, иҗатларының ни дәрәҗәдә сәнгати камиллеге, халыкны тәрбияләүдәге, үзаңын үстерүдәге роле суммада исәпкә алынмау борчый. Галимҗан Ибраһимов та әдипләрнең хезмәтен бәяләүдә шушы ук фикерне кат-кат кабатлаган. «Яңа әдәбият» хакындагы тәнкыйтьләр мөнәсәбәте илә» язмасында 1914 елда Гали Рәхимнең мәктәпләр өчен хәзерләнгән хрестоматиядән чыгып, ул: «Искәндәрев, Туйкин, Шәммаси, Атлаши – болар кемнәр?» дигән соравына каршы «Менә бу сорауны көлми укырга мөмкин түгел! Теләсә кем булсыннар, анысы безгә ник кирәк? Әсәрләре алдымызда, тәнкыйть итәчәк булсак, исемнәренә бәйләнергә түгел, язуларын укырга да, ярыймы, дәрес китабына керерлекме – шул ягын карап хөкем чыгарырга кирәк. /.../ әсәрнең әдәби мәртәбәсе иярәнең шөһрәте белән үлчәнә торган булса, аңа кушыла алмыйбыз. Әсәрен исем белән үлчәү бу – гавам эше, урам эше, зәвекъсыз мәхрүмнәр эше. Без аннан еракмыз», – дип җавап бирә.

Хак сүзләр. Шул ук вакытта каләмдәшләребездән һичкем ниндидер сәбәпләр аркасында танылмаган, үзен танытырга ашыкмаган бер әдипнең, гениаль әсәр язып та, тегe яки бу премияне аласына ышанмыйдыр дип беләм. Хәер, югары дәрәҗәләргә ия булмаган, урында утырмаган язучының Тукай премиясенә юлы бик сикәлтәле, аны бик аз көрәшчеләр генә, анда да иманлы каләмдәшләренеңме, башка берәүләрнеңме ярдәме белән генә ахыргы сантиметрына кадәр уза аладыр, узгандыр дигән карашта торамын. Хөрмәтле укучым, алдагы елларда Тукай бүләген алучыларның исемлеген алдыңа куй да ничә гади язучының аны ала алганын санап чык. Авыр эш булмас. Каләм алып торма. Кул бармакларың җитәр.

Сүз уңаеннан, Галимҗан Ибраһимовның аталган мәкаләсеннән шушы юлларны язып үтәргә телим: «Бик мәшһүр исемнең гомер буена чүбек сатуы, әмма биш-ун кешегә генә мәгълүм бер куәтнең язган бер-ике бит нәрсәсенең саф алтын булуы бик мөмкин хәлдер».

Мин, гомумән, базар һәм урам кашында бик шөһрәткә чыкканнарга шөбһә белән, ышанычсызлык белән карыйм. Боларның күп чүбекләре арасыннан асыл җәүһәрләрне табып чыгару өчен, бик дикъкать белән тикшерү кирәк дип беләм. Шуңа илә бәрабәр, һич тә мәшһүр булмаганнардан вакытвакыт хәкыйкый энҗеләр чыгып куйганын күреп шатланам.

Күктә кайбер йолдызлар ялгыз яна. Әдәбият дөньясында гомуми фикер бирергә теләүчеләр моны һичбер вакыт хәтердән чыгармаска тиешлеләр».

Их, кайбер дөм сукырларга шул йолдызларны төртеп күрсәтергә иде. Милли хәрәкәтнең башында торып та, әдәбиятта үз сүзен әйтергә вакыт тапкан, үз юлын булдырган, үз сәнгати иҗегендә, әмма гомуммилли стиль калыплашуга хезмәт итеп язган, хәтта ки ялгыз диярлек янган, әчтән сызган Фәүзия Бәйрәмова, Айдар Хәлим һәм кайбер башка шәхесләр кабызган йолдызлар яктылыгы күзләрен ачмасмы?..

«Балалар – балалар өчен»

Казанда концерт була, дигән хәбәр берәүне дә шаккатырмый инде бүген. Миллионлы башкалабызның төрле почмакларында андый концерт-тамашалар көн саен дистәләп уза торгандыр.

Ләкин шулай булса да, 3 апрель көнне Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында уза торганына аерым мөнәсәбәт, аерым игътибар. Чөнки ул хәйрия концерты, аны оештыручылар һәм катнашучылар бик игелекле гамәл кылырга җыенганнар, кергән керем белән Казан хосписына ярдәм итәргә булганнар.

– Халыкта хосписны «фәрештәләр йорты» дип атыйлар һәм, нишләптер, еш кына югалтулар, үлем белән бәйләргә тырышалар. Бу алай түгел, зинһар, шул хакта матбугатта языгыз әле, – дип, каләм иярәнә үтенечен белдерде Анжела Вавилова исемендәге Хәйрия фонды җитәкчесе Владимир Вавилов. – Сабыйларның яшәмичә үк якты дөньядан китүләре бик авыр, гаделсезлек, билгеле. Балалар дөньяга яшәр өчен килә, үләр өчен түгел. Хосписның балалар бүлегендә югалтуларның 15 процент кына булуы да шул хакта сөйли. Бу да кечкенә сан түгел. Ә менә өлкәннәр бүлегендә явыз үлем белән ешрак очрашабыз. Сабыйлар, бәхеткә, үзләре дә озаграк яшәргә тырышалар, тормышка теш-тырнаклары белән ябышалар. Мисалга хоспис пациенты – өч яшьлек нәни Азаматны гына алыйк. Журналистлар белән

очрашуга аны әнисе Елена Самадова алып килде.

Малайның аяусыз язмышы хакында аның әнисе Елена ханым тәфсилләп сөйләде. 2014 елда чебен-черкигә куелган сеткага тотынып, нәни Азамат зур биеклектән егылып төшә. Табиблар, чын мәгънәсендә, могҗиза кылалар, сабыйның баш сөяген кыйпылчыклап җыялар. Бала бик озак яшәү белән үлем арасында була, гомере бетмәгәнгәдер инде, бәхеткә, дәвалануны хосписта дәвам итәргә туры килә аларга. Биредә эшләүче персоналның җылы мөнәсәбәте, назы, мәхәббәте, хоспистагы уңай шартлар малайның сәламәтлегенә күзгә күренерлек яхшырта. Ул инде хәзер елмая да белә, төрле авазлар да чыгара. Матбугат конференциясендә дә егет икәнен күрсәтте: елап көйсезләнмәде, әнисен борчымады, китап карап утырды. Тиздән тәмам савыгыр дип көтәләр табиблар. Алардан да ныграк әнисе көтә бу көнне.

Авыр чиргә дучар булган сабыйларның гомерен озынайту һәм авырту-сызланударсыз гына икенче дөньяга китү мөмкинлеге тудырылган хосписта. Өлкәннәр бүлеге дә ачылган. Владимир Владимирович инде хосписның икенче корпусын оештыру уе белән йөри башлаган. Чөнки яман чир дә, башка каты авырулар да яшенә-картына карамый, кешелеккә һөҗүм итәләр. Аларга каршы көрәшкә мондый хоспислар мөмкин кадәр күбрәк кирәк. Ул инде Казаннан ерак түгел генә урман эчендә бер комплекс та тапкан. Хуҗалары хакын да шактый киметкәннәр. Ләкин шулай да, аны сатып алу өчен генә дә (ә бит әле аны җиһазлыйсы да бар) күп нульле сумманң булу кирәк. Хосписта дәвалану да, алты тапкыр тиешенчә диеталы ашату балаларга да, аларның әти-әниләренә дә бушлай. 3 апрель көнне кичке җиденче яртыда булачак концертта Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка мәктәбендә укучы төрле конкурслар лауреатлары исемен яулаган талантлы һәм тырыш балалар катнашачак. Программаның авторы һәм оештыручысы – Муса Җәлилнең оныгы Татьяна Малышева. Концертта Җәлилнең оныкчыклары да катнашачак. Кунакка Чулпан ханым да килер дип көтелә.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

ТУКАЙГА ТУГРЫЛЫК

Тәлгат Галиуллин, сайланма әсәрләренең биш томлыгында басылган «Сәет Сакманов» роман-трилогиясе («Тәүбә», «Элмәк», «Төнге юллар» романнарыннан тора), «Яктылык» исемле әдәби тәнкыйть мәкаләләре тупланган китабы һәм татар әдәбиятын пропагандалаган өчен, Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан 2017 елда Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде.

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТ

Узган гасырның 60нчы елларында әдәбият мәйданына «Кияү», «Спид вә мәхәббәт», «Туган көн», «Урман хуҗасы», «Ниткән хат ул?» дигән гыйбрәтле вакыйгаларны һәм персонажларны юмор-сатира, ирониягә салып тасвирлаган хикәяләре, аннан соң «Замана балалары» (1993), «Дәгъва» (1995) исемле документаль-публицистик повестьлары белән яңача, кыю атлап килеп кергән Тәлгат Галиуллин «Сәет Сакманов» роман-трилогиясен язып, татар әдәбияты түрендә үзенең ныклы, лаеклы урынын яулап алды. Киң җәмәгатьчелек, әдәби тәнкыйть һәм күпсанлы укучыларның бу әсәргә карата биргән уңай бәяләмәсе шул хакта сөйли. Хәер, уңай бәя бирелде дип әйтү генә аз булыр: әсәр әдәби тәнкыйтьне, әдәби фикерне, әдәби хәрәкәтне уятып, җанландырып җибәрде.

Ни өчен дигәндә, «Сәет Сакманов» роман-трилогиясе, иң беренче чиратта, яңа заман үзе тудырган яңа форматтагы киң социаль-психологик, лирик-драматик, логик-фәлсәфи әсәр буларак игътибарны җәлеп итте. Әсәрдә герой-персонажларның эш-гамәлләре, холык-фигыльләре яшәеш, әдәп-әхлак кануннарыннан читкә тайпылганда, ягъни гадәттән тыш шартларда аеруча ачык булып гәүдәләнә. Автор анда бүгенге кырыс, рәхимсез чынбарлыкны бөтен кискенлеге, тулылыгы белән ачып тасвирлый. Бу җәһәттән чыгып бәяләгәндә, роман-трилогиянең төп герое Сәет Сакманов – бүгенге әдәбиятның тулы канлы, булдыклы, гаярь, шул ук вакытта фаҗигале язмышка тап булган яңа заман – социализмда ирешелгән гуманистик, әдәп-әхлак казанышларыннан чигенү, акчага табыну, аның колына әйләнү, кыргый капитализмга кире кайту чоры герое буларак кабул ителә. Роман-трилогия нәкъ менә шул яңалыгы, шул чорның төп героен беренчеләрдән булып тасвирлап-сурәтләп бирүе белән башка әсәрләрдән нык аерылып тора. Аны шундый итеп бүгенге җәмгыять үзе тудырган һәм ул аны үзе үк шундый язмышка дучар итә, Сәет Сакманов шул җәмгыять тудырган адәм актыгы кулыннан һәлак була.

Билгеле, трилогиядә тормышның караңгы, күләгәле якларын гына түгел, соклангыч матурлыгын да якты, җете, ачык буяуларны, ягымлы, дәртле, җилкендергеч сүзләрне мул кулланып тасвирлый автор. Зөлфия образы – шуның матур үрнәге. «Зөлфия кыр чәчәкләре кебек сирпелешеп утырган озын керфекле, ачык, якты маңгайлы кыз; йөзе ачылган чәчәк кебек матур, килешле борынлы, озын муенлы. Зөлфиягә Исхак абзый белән Рәмзия ханым бүләк иткән табигать күлмәгенә тиңдәш, көндәш булырдай кием-салымны дөньяның иң гаярь остасы да тегә алмас иде. Зөлфия – оҗмах кошы, таң нуры».

Безнең әдәбиятта галим-тәнкыйтьчеләрнең чынлап торып проза жанрына күчүләре сирәк күренеш, юк дәрәҗәсендә диярлек дә булыр иде, әгәр бу жанрга күчеп, Тәлгат Галиуллин тәнкыйтьтә генә түгел, проза остасы да булып танылмаса. Безнең көннәрдә барган, башкалар тирәнтен үтеп керә алмаган тема, вакыйга, персонажларны кайнап торган тормыш мәйданында күрсәтү теләге белән алына ул бу жанрга һәм тиз арада үзен документаль, сәнгатьле проза остасы итеп таныта.

Димәк, прозага күчүенең җитди сәбәпләре, ныклы җирлеге булган. Әйтик, табигате белән җор күңелле, юмор һәм ирониягә бай, үткен телле Тәлгат Галиуллинның язучы өчен аеруча кирәкле бу сыйфатларының фәндә һәм әдәби тәнкыйтьтә тиешенчә ачыла алмавы, шуның белән бергә җәмгыятьтә барган демократик үзгәрешләрне, шуңа бәйле рәвештә кешеләр арасында килеп туган катлаулы мөнәсәбәтләрне ничек бар, шулай итеп тасвирлап бирү омтылышы рухландырган.

Тәлгат Галиуллинның гыйльми-педагогик эшчәнлеге турында да бик озаклап һәм тәфсилләп сөйләргә булыр иде. Кыскача гына әйткәндә, аның хезмәт юлы үзе укыган Казан дәүләт университетында ассистент булып эшләүдән башлана. Аннан соң СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтында кече гыйльми хезмәткәр, Алабуга педагогия институтында укытучы, укыту һәм фән эшләре буенча проректор, ректор, Казан педагогия институтында рус әдәбияты кафедрасы профессоры, Казан дәүләт университетында татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетын оештырып, ун ел чамасы шуның деканы, татар теле һәм әдәбияты укыту методикасы кафедрасы мөдире, Россия Федерациясенең милли телләр һәм әдәбиятлар буенча докторлык диссертациясе яклау Советы рәисе вазифаларын башкара. Мондый бай һәм нәтиҗәле хезмәт эшчәнлеге аның әдәби иҗатына да зур, уңай йогынты ясый, әлбәттә.

Әдәби тәнкыйть өлкәсендә 60нчы еллар уртасында дөнья күргән «Яңа үрләр яулаганда» (1972), «Еллар юлга чакыра» (1975) дигән гыйльми-тәнкыйди китапларында башлаган фикерләрен галим 70нче елларда тагын да киңрәк һәм тирәнрәк колачлап дәвам итә. «Социалистик реализм юлыннан» җыентыгында (1977) һәм ике телдә нәшер ителгән «Заман сулышы» – «Дыхание времени» (1979) монографиясендә татар прозасының Бөек Ватан сугышына кадәрге чорын өйрәнүгә, ә инде «Безнең заман – үзе җыр» (1982), «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» (1985), «Дәвамлык» (1987), Мәскәүдә рус телендә чыккан «Здравствуй, поэзия»! (1987), «Илһам чишмәләре» (1988), «Гомер учагы» (1991), «Шигърият баскычлары» (2002), «Шәхесне гасырлар тудыра» (2003), «Әдәбият – хәтер хәзинәсе» (2007), «Яктылык» (2011), «Мәһдиев йолдызлыгы» (2013) исемле хезмәтләрендә һәм алда әйтелгән биш томлыгында (2016) үткән мирасны җентекләп тикшерү белән бергә, танылган галим-тәнкыйтьче бүгенге әдәби хәрәкәтне һәрьяклап, тирәнтен анализлауны күздә тотып яза.

Шунысын да ассызыклап әйтергә кирәк, Тәлгат Галиуллинның Тукай иҗаты белән кызыксынуы да үткән гасырның 60-70 нче елларында ук, шигърият белән халык авыз иҗаты арасындагы багланышларны тикшергән вакытлардан башлана һәм ул аны 90нчы еллардан бирле фәнни юнәлештә өйрәнә. «Г.Тукай һәм XX гасыр татар шигърияте» (1997), «Тукайның Җаек чоры иҗаты – дөнья әдәбияты югарылыгына беренче адым» (1997) дигән мәкаләләрендә, «Шигърият баскычлары» исемле китабында (2002) тәнкыйтьче-галим төп игътибарны шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗатын яңа буынга заманча аңлатып бирүгә юнәлтә.

«Шәхесне гасырлар тудыра» (2003) дигән хезмәтендә Тукайның үз иҗатын һәм татар шигъриятен дөнья поэзиясе үрнәкләре белән баетуын аңлатып бирә.

«Тукай шигырьләрен яңадан укыганда», «Яктылык» китабындагы «Дөньяда аз булыр чын шагыйрь», «Тукай: шәхес һәм шигърият бердәмлеге» дигән мәкаләләрендә галим Тукайның татар халкына хас иң гүзәл сыйфатларга ия булган шәхесенең һәм шигъриятенең бербөтен булуын тасвирлый.

Болардан тыш ул Әнкарәдә чыга торган «Кардәш каләмнәр» журналында басылган «Халык шагыйре Габдулла Тукай» мәкаләсендә төрки халыкларны шагыйрь иҗаты белән таныштыра. Шагыйрьнең сайланма әсәрләре тупланган китабына рус, татар телләрендә язылган «Фаэтон весны» мәкаләсендә һәм «Диалог национальных литератур», «Западноевропейская классика в переложениях Тукая» дигән хезмәтләрендә шагыйрьнең һәр очракта милли шагыйрь булып калуы, иҗатының яңа буын шагыйрьләргә үрнәк булуы һәм зур йогынты ясавы турында әйтелә. Тукайга багышланган башка хезмәтләрендә һәм, әлбәттә, гыйльми-педагогик эшчәнлегендә Тәлгат Галиуллинның әдәбиятны пропагандалауга да зур өлеш кертүе шулай ук аерым игътибарга лаек.

Тәлгат Галиуллин, талантлы прозаик булу белән бергә, киң танылган, иң абруйлы тәнкыйтьчеләрнең берсе: өч-дүрт дистә ел дәвамында ул поэзия һәм проза тәнкыйте дилбегәсен үз кулында тота дияргә була. Шуның белән бергә аның үз иҗаты турында да каләмдәшләренең берничә дистә бәяләмәсе дөнья күрде. Тәлгат Галиуллинның әдәби-гыйльми эшчәнлегенә югары бәя биреп язылган ул мәкалә, очерк, рецензияләрдән тирән эчтәлекле, зур әһәмияткә ия булган бик күп мисаллар китерергә булыр иде.

Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин әдипнең иҗатына мондый бәя бирә: «Сәет Сакманов» трилогиясе аны бүгенге көннең әйдәп баручы прозаиклары рәтенә күтәрде. Гомумән, хәзерге татар әдәбиятында Тәлгат Галиуллин кебек олпат әдипләребез сирәк. Әдәби-иҗтимагый тормышыбызда ярты гасырдан артык үзенең шифалы йогынтысын сиздереп килә ул. Заманында – узган гасырның 70нче елларында – Советлар иленең югары уку йортлары арасында иң яшь ректор булуы гына да күп нәрсә аңлата».

Шунысын да әйтик, Тәлгат Галиуллин әдәби тәнкыйтьнең мөмкинлекләрен, асыл сыйфатларын ачып, аны гаделлек принциплары нигезендә заманча, гуманистик, чын мәгънәсендә демократик рухтагы яңа баскычка күтәрүнең матур үрнәкләрен бирде. Шуның белән бергә ул бүгенге әдәби хәрәкәттә иң актив катнашучы язучы галимнәребезнең берсе: әдәби-музыкаль кичәләрдәге даими чыгышлары, Язучылар берлеге идарә әгъзасы, берлеккә кабул итү комиссиясе вазифаларын нәтиҗәле итеп башкаруы – шуның ачык мисалы.

«Сәет Сакманов» роман-трилогиясе, «Яктылык» исемле әдәби-тәнкыйть мәкаләләре һәм татар әдәбиятын пропагандалауда ирешкән казанышлары белән ул әдәбият-сәнгать өлкәсендәге иң югары бүләк – Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, һичшиксез, лаеклы язучы-галим, тәнкыйтьче.

Хәнәфи БӘДИГЫЙ,
шагыйрь, галим.

КУНАК БҮЛМӘСЕ

Гөлфия Фәйзерахманова:

«Кинода үземне танымадым»

Чаллы театрының танылган артисты Гөлфия Фәйзерахманованың менә дигән балыкчы да икәнен бөтен кеше дә белмидер әле. Иренең туган ягы – Саба районы Олыяз авылына кайтып, балыкка баргач, Нургали әфәнденең кармагын балыклар урап узса, Гөлфия ханым аларны берсе артыннан берсен чүпләп кенә торган.

Линар ЗАКИРОВ

«НИК МИНЕ АЛМАДЫГЫЗ?»

Утыз елдан артык сәхнәдә балкучы Гөлфия ханымны, билгеле, балыклар гына түгел, тамашачылар да, театр тәнкыйтьчеләре дә үз итә. Ильтани Илялова Чаллы театры актрисасының Туфан Миңнуллинның «Саташу» спектаклендәге Мөслимә роленә «ювелирларча башкарылган эш» дип югары бәя бирсә, Татарстанның халык артисты Илдар Хәйруллин аны «интуитив», ягъни сәхнәне үтә дә сизгер тоючы актриса дип атый.

Күптән түгел Татарстанның атказанган артисты Гөлфия Фәйзерахманова 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Без аның тормышындагы иң якты сәхифәләрен барладык.

– Беренче тапкыр сәхнәгә сигезенче класста аяк бастым, – дип сөйли башлады ул. – Клуб мөдире «Үги кыз» әкиятен сәхнәләштерде. Шул спектакль белән районара конкурс-смотрга баргач, жюрида утыручылар, миңа игътибар итеп: «Талантыгыз бар, сезгә театр юлын сайларга кирәк», – диде.

Клубта җыештыручы булып эшләүче әниемә ияреп, булышырга бара идем. Туган авылым (Саба районы, Эзмә авылы) юл өстендә булгач, артистлар бик еш килә иде. Халык, клубка сыймагач, рамнарны алып, тәрәзә төпләрендә утырып та тамаша кылды. Әнинең уң кулы буларак, артистларга чәй илтәм дә, сәхнә артында качып, спектакльләрне шуннан карап утыра идем.

Казандагы театр училищесына керергә дип районнан биш кеше имтихан тапшырдык. Дүртесе керде, ә мин төшеп калдым. Шунысы хикмәт: соңыннан берсе дә тормышын театр белән бәйләмәде. Сәхнә теле укытучысы Асия Хәйруллинадан: «Нишләп мине алмадыгыз?» – дип сорадым. «Сеңлем, син артык тыйнак. Безгә ут чәчеп торучы кызлар кирәк», – диде.

Төшенкелеккә бирелмичә, Алабугадагы мәдәни-агарту училищесында бәхетемне сынап карарга булдым. Барлык имтиханнарны «бишле»гә биргәч, комиссиядәге укытучылар: «Ник театр училищесына бармадың?» – дип сорадылар. Алмаганнарын әйткәч, алар бик аптырады. Училищены тәмамлагач, Минзәлә театрына эшкә кердем. Башта эпизодка гына керттеләр, аннары Рабит Батулланың «Каерылмасын канатың» спектаклендә 22 яшемдә 13 яшьлек малайны уйнадым. Бик зур роль иде ул.

Театр белгече Гали Арсланов, спектаклебезне карагач, «Социалистик Татарстан» газетасындагы мәкаләсендә мине мактап телгә алган иде. Спектакль беткәч, тамашачылар да, сәхнә артына кереп, «Сез, чыннан да, хатын-кызмы? Малай түгелме?» – дип, мине тотып-тотып карадылар.

Гөлфия ханым белән Минзәләдә эшләгән чакта төшерелгән фотоларны карап утырабыз. Шуларның берсендә – артист егет-кызлар арасында сөекле композиторыбыз Сара Садыйкова да елмаеп утыра.

– Гөлшат Зәйнашеваның «Яшел сумка» спектаклендә музыканы Сара апа язып, безгә җырларны ничек башкарырга кирәклеген өйрәтергә килде. Аның пианинода уйнаган чагы. Пианино өстендә паспорты ята. Кайсыдыр егетебез, композиторның ничәнче елда туганын белергә теләп, документына үрелгәч, Сара апа пианиноны кинәт шапылдатып япты да сикереп торып: «Сиңа ник кирәк ул?» – дип, паспортны тартып алды. Менә бит нинди сизгерлек.

Театр директоры аңардан: «Сезне ничек кайтарып куйыйк: самолет, автобус яки машина беләнме?» – дип сорагач, «Үзеңнең машинаң белән кайтар. Кырларны, урманнарны карап, табигатьне күзәтеп кайтасым килә», – диде.

Ике елдан соң, Гөлфия Фәйзерахманова, кияүгә чыгып, Чаллыга күченеп китә. Биш ел хәрби янгын сүндерү бүлегендә эшләп, сержант званиесенә җитә.

– Тормышымда, ни хикмәттер, барлык теләкләрем кабул була. Чаллыда татар театры ачылсын иде, дип хыяллана торгач, көннәрдән бер көнне теләгем кабул булды. Ул вакытта авырлы идем,

шуңа да өченче сезонда гына эшкә килдем. Анда миңа шулай ук зур һәм җаваплы роль тапшырдылар, «Сөясеңме, сөймисеңме?» спектаклендә 80 яшьлек Фатыйма карчыкны уйнадым.

– 13 яшьлек малайдан соң 80 яшьлек карчыкны уйнагансыз булып чыга. Менә бит нинди киң диапазон. Әмма соңгы елларда сез сәхнәдә, нигездә, әбиләр ролендә генә күренәсез...

– Мин бит әбиемнең итәгенә тагылып үстем. Күршедә бик тә җор телле Канифә әтти тора иде. Әбиләрне уйнаганда, аның да күп кенә чалымнарын кулланам. Ул безгә кереп, җырлап, такмак әйтеп чыгып китә иде. «Тагын берне генә җырла инде», –дип ялынып, теләгем үтәлмичә, аны җибәрми идем.

«Аты барның дәрте бар» спектаклендә шулай ук әби булып уйнаганнан соң: «Кареле, нәкъ үзеңнең Шәмсувафа әбиеңә охшагансың», – диделәр. Миңа бер тамашачы: «Әбиләрне генә уйнагыз әле. Сезгә шулкадәр килешә», – диде.

БИБИНУРНЫҢ ТУГАНЫ

– Үземне педагог буларак та сынадым. Чаллының 48нче мәктәбенә театр түгәрәгенә җитәкче булып барып, җиде ел эчендә балалар белән спектакльләр чыгардык, кичәләр үткәрдек. Шәһәрнең 24 театр коллективы арасында Фәнис Яруллинның «Ак яфрак» әсәре белән беренче урынны алдык.

«Ак яфрак»та уйнаган укучыларым – гаҗәеп оста, коеп куйган артистлар иде. Барысы да сәхнә юлын сайлар, дип уйладым. Ул балалар миңа күктән төшкән бүләк булды. Репетицияләрдән соң, караңгы төшкәч, кайберләре кайтырга куркып, аларны өйләренә кадәр озата идем.

– Гөлфия ханым, үзегезне кинода да сынап карагансыз икән бит...

– «Бибинур» фильмында төшерү өчен, республика театрларында эшләүче артистлар арасында кастинг үткәрделәр. Чаллыдан мине һәм Рафик Каюмовны сайлап алдылар. Кинофильмда эпизодта Бибинурның туганын уйнадым. Грим салганнан соң, үземә бер дә охшамаган идем. Хәтта киноны караганда үземне танымадым.

Шул бер эпизодта төшәр өчен, Камал, Түбән Кама, Буа театры артистлары белән өч көн агач башында утырдык. Безне анда кран белән менгереп, чылбыр белән бәйләп куйдылар, агач кәүсәләренә такта, киез дә җәйделәр. Ашарга да кран белән генә җибәрделәр.

– Бернечә секундлык өлешне төшерү ник шулкадәр озакка сузылды?

– Сценарий буенча агач тирәли төтен җибәрәләр. Әмма җил аркасында ул бер мизгелдә тарала да бетә. Шуңа да төтенне кат-кат җибәрергә мәҗбүр булдылар.

Фильмда әзерлек эшләре бик күп вакытны ала. Аны көз көне төшерделәр. Үзәккә үтәрлек суык булды, җитмәсә, яңгыр да яуды. Көненә сигез сәгать буе юка күлмәктән утырдык. Кайткач, күбебез чирләп бетте. Шушы хәлләрдән соң, кинода төшкәнче, рәхәтләнеп спектакльдә уйнар идем, дидем үз-үземә.

«АЯК АСТЫНДА АУНЫЙСЫЗ»

– Тамашачы, сәхнә артына кереп, артистлар тормышы белән кызыксынамы?

– Туган көнем булган көнне спектакль дә, репетиция дә булмады, шуңа да эшкә бармадым. Бер тамашачы, театрга килеп, мине эзләп йөргән. Ул, телефон номерымны табып, икенче көнне шалтыратып, туган көнем белән котлады. Аның: «Сәхнәдән бер сүз сөйләмичә утырып кына торсагыз да, безгә шулкадәр рәхәт», – дип әйткәне бар.

Районнарда гастрольләр белән йөргән чак. «Аты барның дәрте бар» спектаклендә картлар булып уйнаганыбызны күреп, тамашачылар: «И-и мескеннәр, болар пенсиядәдер инде, яшьләренә акча җитми торгандыр», – дип, безне ихластан кызганып куйганнар. Юкса, без ул вакытта 40-45 яшьләрдә идек.

– Ничек уйлыйсыз, узган гасыр белән чагыштырганда, XXI гасыр тамашачысы үзгәрдеме?

– Телевизордан сериаллар күрсәтелә башлагач, халык театрга йөрми башлады. Менә хәзер Зифа Кадыйрова безгә тамашачыны кире кайтарды. Былтыр Чаллы театры аның «Язмыш сынавы» әсәренә нигезләнеп язылган спектаклен чыгарды. Театр ишеге кайсы якка ачылганын да белмәгән күпме кеше килеп карады шуны.

«Язмыш сынавы»нда спектакльнең режиссеры Илдар абый Хәйруллин Гарифә роленә мине үзе билгеләде. Юкса, бу образны башкарырга теләк белдерүчеләр күп булды. Спектакль чыккач, Илдар абый: «Сине сайлап ялгышмаганмын», – диде.

– Чаллы театры бик кечкенә бинада урнашкан, сәхнәгез дә бик сәер генә, тыңлаусыз балаларны бастырып куя торган бер почмакка охшаган. Шундый шартларда эшләү кимсенү хисе тудырмыймы?

– Берсендә урамда янгын сүндерү бүлегендә бергә эшләгән полковникны очраттым, аны «Кодача» спектаклендә чакырдым. Икенче юлы очраткач, ул: «Театрыгызга бүтән бармыйм, сеңлем. Артистларны бик җәлләдем, сез бит тамашачының аяк астында ауныйсыз», – диде. Дөрестән дә, сәхнә тамаша залыннан бер метр биеклектә булырга тиеш, ә без түбәндә уйныйбыз, тамашачының аяк астында.

Башкортстандагы «Нур» татар театры әнә нинди мәһабәт бинада урнашкан. Зурлыгы буенча Татарстанда икенче урында торган Чаллы шәһәрендә милли театрга лаеклы бина таба алмаулары күңелне рәнҗетә.

КЫСЛА ТОТУЧЫЛАР

– Мин Мишә буенда үстем. Энекәшләр белән язын ташу вакытында ятьмә белән көнозын балык тота идек. Әби шул балыкны мичтә киптереп, без кылчыгы-ние белән шытыр-шытыр ашый идек. Балык тоту тынычландыра да бит әле.

Берсендә ирем Нургали белән Минзәләгә Ык буена бардык. Кармакны салган саен, кысла эләгә. Ярты чиләк тотып, барысын да кире җибәрдек.

«Язмыш сынавы» спектакле белән Зифа Кадыйрованың туган ягы – Башкортстанның Учалы районына гастрольгә баргач, Өрген дигән гаҗәеп зур күлдә тукталып, театр директоры Рашат Фәйзерахманов белән ярыша-ярыша балык тоттык. Җитәкчебез сатып алынган кармак белән коралланган иде, мин дә сәхнәдәшем Булат Сәлахов чыбыктан ясап биргән җайланмага шактый балык эләктердем.

Нияз Бишбалта төзеде.

Чайнворд

«Дөнья халыклары»

1. Улан-Удэда яшәүче халык.
2. Казанда яшәүче халык.
3. Бухарестта яшәүче халык.
4. Ослода яшәүче халык.
5. Мәккәдә яшәүче халык.
6. Варшавада яшәүче халык.
7. Астанада яшәүче халык.
8. Абаканда яшәүче халык.
9. Белградта яшәүче халык.
10. Уфада яшәүче халык.
11. Истанбулда яшәүче халык.
12. Паланада яшәүче халык.
13. Нукуста яшәүче халык.
14. Элистада яшәүче халык.
15. Нальчикта яшәүче халык.
16. Кавказда яшәүче халык.
17. Мәскәүдә яшәүче халык.
18. Норвегиядә яшәүче халык.
19. Йошкар-Олада яшәүче халык.
20. Апеннин ярымутравында яшәүче халык.
21. Берлинда яшәүче халык.

Җаваплар.
1.Бурят **2.**Татар **3.**Румын **4.**Норвег **5.**Гарәп **6.**Поляк **7.**Казах **8.**Хакас **9.**Серб **10.**Башкорт **11.**Төрек **12.**Коряк **13.**Каракалпак **14.**Калмык **15.**Кабарда **16.**Авар **17.**Рус **18.**Саам **19.**Мари **20.**Итальян **21.**Немец.

Бөтен кызыклы мәгълүмат бер урында www.shahrikazan.com

Кечкенә юмор

Шаяннар һәм тапкырлар клубында (ШТК) дусты булган кешедән дә бәхетлерәк кеше юктыр ул. Кәефең нинди булуга карамастан, яңа көлке «дозасы» кабул итәсең дә көн буе елмаеп йөрисең. Ә елмаю, үзегез беләсез, тормышны озынайта, яшәүгә ямь өсти.

29 март көнне Татарстанның Халыклар дуслыгы йортында көлке «дозасын» күпме телисең, шуның кадәр кабул итәргә була иде. Көлдерүчеләре – әле бу өлкәдә канат кына чыгып килүче мәктәп укучылары. Шаяннар һәм тапкырлар клубындагылар фикеренчә, балалар юморы аеруча үзенчәлекле. «Яшел Үзәк», «Фәрит абый», «Авиарежим», «КҖК», «ББК», «Оекбаш», «Теге ни», «Оба-на» (Чаллы) дигән сигез команда көндәлек актуаль проблемалардан рәхәтләнеп көлде. Балалар юморы мәктәп темасы кысаларыннан чыкмас дигән идем, алар «Инстаграм»да бара торган «туры эфир», татар эстрадасы, беренче мәхәббәт, аталар һәм балалар темаларын, хәтта татар теле үзенчәлекләрен дә юмор аша күрсәтә алды.

– Казанда мәктәп укучылары арасында ШТК уеннарын инде җиденче тапкыр оештырабыз. Безнең балалар бары тик татарча гына көлдерә, бу үзенчә – яшьләрдә туган телгә, милләтебезгә карата мәхәббәт уяту. Балалар белән ел әйләнәсендә кураторлар эшли. Алар укучыларга кызыклы номер куярга ярдәм итә. Быел безнең иң яшь сезон. ШТКчылар – 7-8нче сыйныф укучылары, – диде мәктәп укучылары арасында ШТК уеннарын оештыручы Гаяз Гыйльманов.

Никтер, кызларда юмор хисе юк, дигән фикер йөри. Ләкин бүгенге ШТК уенында, егетләргә караганда, үткен телле, зирәк фикерле кызлар күбрәк иде. Шуларның берсе – Авиатөзелеш районының 14нче гимназия укучысы Лиана Зәйнуллина. Ул менә өченче ел инде «Яшел Үзәк» командасында чыгыш ясый. Шуңа өстәп, вокал буенча төрле конкурсларда катнаша.

– Берсүзсез, егетләр мәзәкләрне яхшырак яза, ләкин кызлар аны сәхнәдә остарак күрсәтә. Һәр хатын-кыз актриса, дип тикмәгә генә әйтмиләр бит инде. Кызларда харизма бар. ШТК безнең өчен күп мөмкинлекләр ача. Әйтик, сәхнәдә үз-үзеңне тотарга өйрәнәсең, кешеләр белән дөрес итеп аралашасың, – ди Лиана.

Алисә САБИРОВА.

АФИША
3-9 АПРЕЛЬ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

3 апрель Разил Вәлиев юбилей кичәсе
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум
4 апрель «Агыла да болыт агыла...» (Х.Туфан, Т.Миңнуллин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 300-350 сум
7 апрель «Ак калфагым төшердем кулдан» (И.Юзеев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
8 апрель «Исәнме, улым!» (Б.Абдураззоков)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 300-350 сум
8 апрель «Ак калфагым төшердем кулдан» (И.Юзеев)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
9 апрель «Ут күршеләр» (С.Юзеев)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

4 апрель «Кияүләр» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30
5 апрель «Беренче мәхәббәт» (И.Гали)
Башлана: 18.30
8 апрель «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин)
Башлана: 17.00
9 апрель «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 300-1000 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

5 апрель «Не хочу, не буду»
Башлана: 11.00
(Сахалинск курчак театры гастрольләре)
7 апрель «Мы летели на диване...»
Башлана: 11.00, 13.00
8 апрель «Я люблю Вас, Ромашка»
Башлана: 10.00, 11.30
8 апрель «Мы летели на диване...»
Башлана: 13.00, 15.00
9 апрель «Я люблю Вас, Ромашка»
Башлана: 10.00, 11.30
9 апрель «Мы летели на диване...»
Башлана: 13.00, 15.00
Билет бәясе: 250-600 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

3 апрель Рафил Җәләлиев белән Эльмира Гыйльфанова концерты
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 400-800 сум

УНИКС
(ПРОФЕССОР НУЖИН УРАМЫ, 2/27)

3 апрель Ришат Төхвәтуллин концерты
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 500-1200 сум
4 апрель Ришат Төхвәтуллин концерты
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 900-1500 сум
9 апрель Дилә Нигъмәтуллина концерты
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 500-1100 сум

«ПИРАМИДА» МӘДӘНИ-КҮҢЕЛ АЧУ ҮЗӘГЕ
(МӘСКӘҮ УРАМЫ, 3)

7 апрель «Түзә йөрәк» Ильвина концерты
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 500-1500 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Язучы Марсель Галиевнең «ТЫНЛЫК ДӘШКӘНДӘ» дип аталган фотокүргәзмәсе
Ачылыш: 7 апрель, 13.00дә
Керү ирекле (эш көннәрендә).

5+

Камал театры үз тамашачыларын сәхнә артына сәяхәткә чакырды. «Дәрсе гыйбрәттер театр ...» дип аталган проект баш режиссер Фәрит Бикчәнтәев белән театр тәнкыйтьчесе Нияз Игъламов идеясе буенча тормышка ашырылды, режиссеры – Илгиз Зәйниев. Текст авторы – шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин. Тамашачылар сәхнә артын да, тамаша залын да, театрның башка урыннарын да күрә ала.

Театрга сәяхәткә

Сәяхәт театр тарихы белән таныштырудан башланып китә. Юлдашлар Алмаз Гәрәев белән Ришат Әхмәдуллин театрның үткән юлын күздән кичерергә ярдәм итәләр. 1906 елның 5 маенда киң җәмәгатьчелек өчен беренче спектакль уйнала. Ул 22 декабрьдә кабатлап күрсәтелә һәм театрның туган көне булып тарихка кереп кала. 1907 елда Мәскәүдә «Сәйяр» труппасы артистлары Ильяс Ашказарскийны театрдан куалар. Алмаз Сабирҗанов, Эмиль Талипов, Фәннүр Мөхәммәтҗанов, Ирек Кашапов, Ләйсән Фәйзуллина тамашачыны узган гасырга алып кайталар.

1932 елда Салих Сәйдәшев (Рамил Вәҗиев) белән Сара Садыйкованың (Гүзәл Гюлвердиева) бер-берсен күрмичә ишек аша гына сөйләшүләре – сәяхәтнең иң кызыклы мизгелләре. Тинчурин, спектакльгә музыка кирәк булгач, Сәйдәшевне бикләп куеп эшләтә. Бу очракта сәхнә алдындагы чокыр аерым бүлмә ролен үти. Сәйдәшев образындагы Йосыф Бикчәнтәев композиторның үзен күз алдына китереп бастыра. Ул Сара Садыйкованы көй язарга мәҗбүр итә.

1937 елда Тинчуриннан сорау алу күренеше аеруча тетрәндерә. Тикшерүченең (Олег Фазылҗанов) төрлечә мәсхәрәләүләренә дә түзә драматург (Фәнис Җиһанша). Ул тикшерүче кәгазенә кул куймый. Аны атарга, дигән хөкем карары чыгарыла һәм 1938 елда үтерелә.

1943 елда театрда «Гроза» спектакле куела. Анда Катерина ролен күренекле артист Фатыйма Ильская уйный. Тәнәфес вакытында почтальон аның кулына телеграмма китереп тоттыра. Улы фронтта һәлак булган. Шулвакыт спектакльне туктатырга, дисәләр дә, ул каршы килә, ахырына кадәр уйнап чыга. Ләйсән Рәхимова Ильскаяның кичерешләрен үз йөрәге аша үткәреп уйный.

Театрның танылган артисты Әзһәр Шакиров Мәскәүдә укыган чорда беренче тапкыр Камал театры спектаклен шунда каравын (1957 елгы декадада), анда СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлиловны күрүе турында журналист (Венера Шакирова) сөйли. 1962 елда яңа гына театрда эшли башлаган Марсель Сәлимҗановны өлкән артистлар Шамуков белән Ильская (Илдус Әхмәтҗанов, Фирая Әкбәрова) бик санларга теләми. Шул чагында яшь режиссерга Хәлил Әбҗәлилов ярдәмгә килә...

Театрга шимбә көннәрендә сәяхәт кылырга мөмкин булачак. Ул 1 сәгать 15 минут дәвам итә. Билет бәяләре – 300 сум.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1668. Гомуми тираж – 6338.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 695. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы